СЫНАЛДЫК, СЫНАТМАДЫК

Узган ел ниләр белән истә калды?

> 7

ИСКЕСЕ ДӘ ЯРЫЙ

Киләсе елда көнкүреш техникасы алырга теләүчеләргә нәрсәгә өметләнергә?

> 15

СӘХНӘ АРТЫНДА

Әдәбият-сәнгать әһелләре узып баручы елга нәтиҗә ясый

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 194 (28967) | Җомга | 30 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены беләән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Анна Арахамия

ХУШ КИЛӘСЕҢ, АППАГЫМ!

2023 ЕЛ – КУЯН ЕЛЫ

2023 елдан нәрсә көтәсе? Ел хуҗасы төсле куркак булмасмы, җитезлеге белән алдыра алырмы? Әллә төсен үзгәрткән шикелле, вакыйгалар меңгә төрләнерме? Гомумән, әлеге җәнлекнең холкына карап киләсе елны фаразлап буламы? Озынколакның күңеленә хуш килер өчен нәрсә эшләргә? Алар нәрсә ярата һәм нәрсәне өнәми? Татарстанда куян үрчетүчеләр белән шул хакта сөйләштек.

> 6



ҺӘР ЙОРТКА БӘХЕТ ИҢСЕН!

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВның ЯҢА ЕЛ МӨРӘҖӘГАТЕ

Кадерле татарстанлылар!

Иң яраткан бәйрәмнәребезнең берсе – Яңа ел якынлашып килә.

Якты өметләр уята һәм игелекле эшләргә җилкендерә торган тылсымлы мизгелләр җитә.

Гадәттәгечә, без бу вакытта үткәннәргә йомгак ясыйбыз, киләчәккә ниятләр корабыз.

2022 ел сынаулар елы булды, әмма алар безнең ныклыгыбызны какшата алмады: бүгенге көндә күпмилләтле халкыбыз һичкайчан булмаганча бердәм. Махсус хәрби операция, илебезнең бәйсезлеге һәм тынычлык хакына көрәшү шартларында без илкүләм лидерыбыз Владимир Владимирович Путин, Ватаныбызны саклаучылар, каһарман сугышчылар тирәсендә тупландык, хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренә ярдәм күрсәтәбез. Безнең рухыбызны сындыра алмаслар, без җиңәчәкбез!

Кыенлыкларга карамастан, икътисадны үстерү турында онытмыйча, барлык социаль гарантияләрне саклауга ирештек.

Иннополис үзенә яңа резидентлар җәлеп итә, «Алабуга» Россиядәге махсус икътисадый зоналарның иң яхшысы дип танылды, Цифрлаштыру елында Татарстанда Бәшир Рәмиев исемендәге ИТ парк ачылды. Бөртеклеләрдән мул уңыш җыеп алдык, республика терлекчелек продукциясе, иң кирәкле азык-төлек продуктлары белән үзен тулысынча тәэмин итә. Нефтьчеләр һәм нефть химиясе, машиналар төзү өлкәсендә эшләүчеләр, энергетиклар, төзүчеләр һәм юл хуҗалыгында хезмәт куючылар татарстанлыларның өлкән буын вәкилләре нигез салган күркәм традицияләрне дәвам иттерә. Укучылар һәм студентларыбыз, белемнәренең киң һәм тирән булуын дәлилләп, халыкара һәм Россия күләмендә уздырылган олимпиадаларда беренчелек яулый. Укытучылар, социаль өлкә хезмәткәрләре, табибларыбыз, һөнәри осталыкларын көннән-көн арттыра барып, федераль дәрәҗәдә танылуга ирешә. Күпләр үз ихтыярлары белән йөрәк җылысын бүлешәләр һәм ярдәмгә мохтаҗлар янына ашыгалар. Хөрмәтле татарстанлылар, бу елны без беренче чиратта сезнең тырышлык нәтиҗәсендә уңышлы тәмамлыйбыз. Мин сезнең һәрберегезгә игелекле хезмәтегез һәм үз-үзегезгә ышанычыгызны югалтмавыгыз өчен олы рәхмәтемне җиткерәм. Барысы да безнең үзебездән тора!

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү аеруча мөһим вакыйгаларның берсе булды һәм тарихи-мәдәни мирасны саклауга, дәүләт һәм дини берләшмәләр арасындагы мөнәсәбәтләрне үстерүгә юнәлтелгән эшнең әһәмияте гаять зур булуын раслады.

2023 ел Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителде. Бу уңайдан уздырыла торган чаралар халыкларның телен, мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен саклауга һәм үстерүгә, дуслык-татулыкны, диннәр арасындагы хезмәттәшлекне, җәмгыятьтәге тынычлыкны ныгытуга ярдәм итәр дип ышанам.

Кадерле дуслар!

Яңа елны каршылаганда җанга якын туганнарның һәм дусларның янәшә булуы һәркемнең күңеленә хуш килә. Дуслыкның, бер-береңә терәк һәм теләктәш булуның, якыннарыңны кайгыртуның кыйммәте хәзерге чорда аеруча арта.

Яңа ел уңышлар алып килсен, олысына-кечесенә ихлас елмаюлар, сөенечләр бүләк итсен, һәр йортка бәхет иңсен!

Сезгә, хөрмәтле татарстанлылар, нык сәламәтлек, иминлек, муллык телим! Яңа 2023 ел мөбарәк булсын!

Районнарда ни хәлләр?

Питрәч

Питрәчнең 1 нче мәктәбенә Россия Герое Иван Додосов исеме бирелде. Туган мәктәбендә узган тантаналы чарада герой үзе һәм аның әти-әнисе дә катнашты. «Бүгенге уңышларымда укытучыларымның өлеше гаять зур. Үзем укыган мәктәпкә минем исем бирелүе белән чиксез горурланам», – диде Иван Додосов. Батыр егет Яңа елны гаиләсе белән бергә каршы алачагын да әйтте. «Бу мәктәп һәрвакыт талантлы, күренекле, көчле рухлы кешеләр белән дан тотты. Шуларның берсе – әлеге мәктәпне тәмамлаган Иван Додосов. Питрәч халкы Россия Герое Иван Додосов белән горурлана!» – диде чарада район башлыгы Илһам Кашапов.
(«Татар-информ»)

Азнакай

Урсай авылында яңа иман йорты ачылды. «Мөхәммәдзакир» мәчетен ачу тантанасында район башлыгы Марсель Шәйдуллин, Татарстан мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары Равил хәзрәт Зөфәров, Татарстанның Көнбатыш төбәк казые Рөстәм хәзрәт Шәйхвәли, мәчет төзелешенең төп иганәчесе Рәсимә Мусина, төрле төбәкләрдән, Уфадан, хәтта Төркиядән килгән кунаклар, авыл халкы катнашты. Рәсимә Мусина мәчетне Урсай авылында туып-үскән, репрессияләнеп, гомерен чит җирләрдә уздырырга мәҗбүр булган бабасы Әбел Фатих Мөхәммәдзакир хөрмәтенә салдырган. Урсай авылы җирлеге башлыгы Зилара Рәхимҗанова белдергәнчә, мәчет янында балалар өчен уен мәйданчыгы төзеләчәк һәм алмагачлар утыртылачак.
(«Азнакай-информ»)

Теләче

Теләче районында кардан биеклеге – тугыз, озынлыгы унбер метрдан арткан куян сыны ясаганнар. Бу дәү куян янында олысы да, кечесе дә фотога төшә. Алай гына түгел, 2023 ел – Куян елы булганлыктан, һәр оешмада, ял паркында куян сыннары ясап куйганнар. Алар гадәти куяннар гына түгел – спортчы куяннан алып, язучы, банкир, агрономга кадәр бар. Шулай итеп, районда үзенчәлекле куяннар саны 1001гә җиткән.
(«Теләче-информ»)

Әлмәт

Якын киләчәктә Әлмәт сусаклагычы ярында яңа ял итү урыны барлыкка киләчәк. «Россиянең Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы уңай шәһәр мохитен булдыру проектларының VI Россиякүләм конкурсына нәтиҗәләр ясады. Без 100–200 мең кеше яши торган шәһәрләр номинациясенә гариза бирдек. Әлмәт – җиңүчеләр исемлегендә! Без 106 млн сумлык грант оттык», – дип хәбәр итә район башлыгы Тимур Нагуманов. Грант акчасы сусаклагычны төзекләндерү проектын гамәлгә ашыра башларга мөмкинлек бирәчәк. Чаңгы яратучылар өчен монда ел әйләнәсендә павильон эшләячәк, ә җәйге ял өчен пляж, барбекю өчен урыннар һәм су янында спорт мәйданчыклары төзекләндереләчәк.
(«Әлмәт таңнары»)

АЛТЫНГА ТИҢ КӨМЕШ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов – икенче! Илкүләм губернаторлар рейтингының еллык йомгаклары билгеле. Әлеге исемлектә республика җитәкчесе Мәскәү мэры Сергей Собянинга гына уздырган. «Рейтинг» мәгълүмати коммуникацияләр үзәге уздырган сораштыруда белгечләр Татарстан Президентына бирелгән зур бәянең асылын да аңлаткан.

№	ЖИТӘКЧЕ	ТӨБӘК
1	Сергей Собянин	Мәскәү шәһәре
2	Рөстәм Миңнеханов	Татарстан Республикасы
3	Рамзан Кадыйров	Чечня Республикасы
4	Алексей Дюмин	Тула өлкәсе
5	Андрей Воробьев	Мәскәү өлкәсе
6	Айсен Николаев	Саха (Якутия) Республикасы
7	Александр Дрозденко	Ленинград өлкәсе
8	Вячеслав Гладков	Белгород өлкәсе
9	Евгений Куйвашев	Свердловск өлкәсе
10	Сергей Цивилев	Кемерово өлкәсе – Кузбасс

Әйтүләренә караганда, республикага федераль дәрәҗәдәге кунаклар еш килә. Аерым алганда, Рөстәм Миңнеханов Россия сәнәгать һәм сәүдә министры Денис Мантуровка тирәнтен модернизацияләнгән Ту-160М ракета йөрткеч-бомбардировщигын күрсәткән. Россия Хисап палатасы рәисе Алексей Кудрин белән сөйләшкәндә, Президент Татарстанны Идел буеның иң тотрыклы һәм көчле үзәге дип атаган. Рөстәм Миңнеханов Россия Иминлек советы сәркатибе Николай Патрушев һәм Идел буе федераль округында вәкаләтле вәкил Игорь Комаров белән санкцияләр шартларында транспорт һәм энергетика куркынычсызлыгы турында фикер алышкан.

Татарстан тышкы сәясәткә бәйле вакыйгаларга да тиешле җавап бирә алды, дигән белгечләр. Республикада икътисадның тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча оператив штаб эшли. Предприятиеләргә ярдәм итү һәм халыкны беренчел кирәк-яраклар белән тәэмин итүгә бәйле план гамәлгә кертелде. Эшкуарларга даими ярдәм күрсәтелә. Донбасс төбәкләренә булышуыбыз турында да әйткәннәр. Моннан тыш, Татарстан Украинадан күчеп кайткан 1 меңнән артык кешене сыендырды.

Рөстәм Миңнехановның ил төбәкләре җитәкчеләре арасында бердәнбер Президент икәнен дә онытмаганнар. «Рәис» тирәсендә бераз бәхәс чыкты, әмма республикада әлеге мәсьәләдә уртак фикергә килделәр, дигән белгечләр.

Фикер

Александр МАЛЬКЕВИЧ,
журналист, сәясәтче:

– Икътисадый шартлар шактый катлаулы булуга карамастан, Татарстанның авыл хуҗалыгы тармагы 100 процент күрсәткечләргә иреште. Игенчеләр 5,2 миллион тонна уңыш җыйды. Татарстан күрше төбәкләрне дә азык-төлек белән тәэмин итә ала. Урып-җыю эшен Рөстәм Миңнеханов шәхсән контрольдә тотты. Республика башлыгы чит илләрдә хезмәттәшләр табу осталыгын да күрсәтте. Быел Татарстанда Фәләстыйн, Таҗикстан, Бәхрәйн, Мьянма, БГӘ кебек чит илләр делегацияләре булды. Рөстәм Миңнеханов Сенегал, Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Казахстан, Иран, Бәхрәйн, Азәрбайҗан, Төркия, Катарга эш сәфәренә барды.

Президент Рөстәм Миңнеханов Глобаль толерантлык һәм тынычлык советы президенты Әхмәд бин Мөхәммәд Әл-Җарван белән очрашты.

Ул Россиядә Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны федераль дәрәҗәдә билгеләп үтүләре турында сөйләде. Россия Президенты Владимир Путинның тырышлыгы белән илдә барлык диннәргә дә ихтирам күрсәтелүен әйтте. «Татарстан – моның ачык мисалы. Республикада күп гасырлар дәвамында мөселманнар һәм христианнар тату һәм дус яши», – диде ул.

Яшьләрдә – өй туе

Яңа ел алдыннан көтелгән һәм көтелмәгән бүләкләр һәркемне куандыра. 28 декабрь көнне Түбән Камада «Җәлил» театраль комплексын – Яшь тамашачылар театрының төзекләндерелгән бинасын ачу әнә шундый шатлыклы вакыйга буларак тарих битенә язылачак.

Бина «Мәдәният» илкүләм проекты кысасында төзекләндерелгән. Хәзер үз сәхнәсенә, зур һәм кече залларга тиенгән коллектив өчен дә, шәһәрнең театр сәнгатенә гашыйк балалары өчен дә чын мәгънәсендә иҗади мәйданда гөрләп яшәр өчен бөтен шартлар барлыкка килгән.

Гадәттә, театр кием элгеченнән башлана дип кабатларга яратабыз, бу юлы «бәйрәм балалардан башланды» дип әйтү дөресрәк булыр. Аларның русча да, татарча да, инглизчә дә, французча да күрсәткән кыска, зәвыклы тамашаларын кунаклар үзләре сабый чакка кайткандай кинәнеп тамаша кылды. Бинаның яңа күлмәк кигән кызлардай балкып торган йөзе белән театр директоры Алсу Җаббарова таныштырып үтте, аннан соң тантана зур залда дәвам итте.

«Мондый бинаның ачылуы – Түбән Кама масштабында гына түгел, республика күләмендә истәлекле вакыйга. Аеруча укытучылар, ата-аналар, балалар сөенеп туялмыйлар. Безнең хезмәт сөючән, күпмилләтле халкыбыз бар өлкәдә дә тырышып эшли, авыл хуҗалыгында булсынмы, мәдәният өлкәсендәме… Төзүчеләргә рәхмәт – ничек ялт итеп эшләп куйганнар!» – дип үзенең котлау сүзләрен ирештерде тантанада Татарстанның Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин.

Бәйрәм бүләксез булмый – театр директорына 100 мең сумлык сертификат та тапшырды. Шәһәр башлыгы Рамил Муллин да үз чыгышында дәүләт җитәкчеләренең, театрны яшәткән һәркемнең хезмәтен бәяләп: «Бу йорт – бина гына түгел, мәдәният учагы. Коллективка аерым рәхмәт – кайда гына булсалар да, аларны энтузиазм ташламый», – дигән фикерен җиткерде.

«2022 елда Түбән Камада байтак кына зур проектлар тормышка ашырылды, «Җәлил» үзәгенең ачылуын исә ел вакыйгасы дияргә мөмкин». – Дәүләт Думасы депутаты Айдар Метшин бәйрәм тантанасын әнә шулай бәяләсә, Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова: «Көннең төп могҗизасы – менә бу артистлар. Мин сезгә ышанам, сез булдырачаксыз!» – дип балаларга канат куйды.

tatarstan.ru

Чара барышында театр хезмәткәрләрен дә, ветеран артистларны да, театрның беренче җитәкчеләреннән булган Татьяна Пляшеваны да хөрмәтләргә онытмадылар. 1994 елдан бирле эшләп килүче Яшь тамашачылар театры моңа тиклем дә шәһәр, республикакүләм, халыкара фестивальләрдә, «Бердәм Россия»нең «Кече шәһәрләр театрлары», «Кече Ватан мәдәнияте» программаларында катнашып, үзләре «Чикләрсез театр» фестивале оештырып, тамашачыларга төрле кызыклы жанрдагы спектакльләр тәкъдим итеп, үз йөзен танытырга өлгергән иде. Яңа бина аларга тагын да зуррак мөмкинлекләр бирер, яңа уңышлар китерер.

Түбән Камада икенче бер бина – Халыклар дуслыгы йорты да шушы бәхеткә тиенер көннәрне зарыгып көтә. Театр ачылышы алдыннан кунаклар анда да булырга өлгергән иде. Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясы Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшинны бирегә 23 иҗтимагый оешманың, 15 милли-мәдәни җәмгыятьнең эшчәнлеге белән кыскача таныштырганнан соң, 1974 елда салынган бинаның бүгенге көн таләпләренә җавап бирмәвен әйтеп, ремонт кирәк дигән үтенечләрен дә җиткерделәр. Беркадәр вакыттан соң ул йортка да, Яшь тамашачы театры кебек, өй туен бәйрәм итәргә насыйп булсын.

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА

ЗИННӘТУЛЛА ҺӘМ АНЫҢ КОМАНДАСЫ

Барысы да көтелгәнчә килеп чыкты. Өч атна ярдәмче булып эшләгәннән соң Зиннәтулла Билалетдиновны «Ак барс»ның баш тренеры итеп билгеләделәр. Бу аның әлеге вазыйфага өченче мәртәбә алынуы, Казан клубына икенче мәртәбә кайтуы. Тәҗрибәле остаз өчен барысы да таныш кебек, тик бу юлы аның вакыты аз булачак.


ak-bars.ru

Декабрь башында Олег Знарок эштән киткәч, баш тренер вазыйфасына Юрий Бабенконы билгеләделәр. Зиннәтулла Билалетдиновны исә аның ярдәмчесе дип игълан иттеләр. Чынбарлык исә нәкъ киресенчә булды. Белгечләр дә, тамашачы да кемнең нинди эш башкарганын тиз чамалап алды. Команда уенында да таныш чалымнар беренче матчларда ук шәйләнә башлады: «Ак барс» ахырга кадәр көрәшергә тырышты, звеноларда тәртип барлыкка килде. Нәтиҗәдә уенчылар тынычланды, үзләреннән нәрсә таләп ителгәнен яхшырак чамалый башлады. Билалетдинов эшкә алынгач, Казан командасы 7 очрашуда 11 очко туплады. Сезон башы белән чагыштырсак, бик яхшы нәтиҗә бу!

Шуңа күрә Зиннәтулла Билалетдиновның рәсми рәвештә баш тренер итеп билгеләнүендә гаҗәпләнерлек берни дә юк кебек. «Команданың уены яхшырды, дисциплина ныгыды. Үсеш барлыгын һәм команданың киләгәнчә уйный алуын күрәбез. Быелгы сезонга төп бурыч шул килеш калды. Безнең турнир таблицасында өскәрәк күтәрелергә һәм плэй-оффка яхшырак әзерләнергә вакыт бар», – ди «Ак барс»ның генераль менеджеры Марат Вәлиуллин.

Тик тәҗрибәле остазның кабат баш тренер вазыйфасына алынуын клуб җитәкчелегенең башка юлы булмау дип тә аңларга мөмкин. Беренчедән, «Ак барс»ка башка белгечләрне чакыру турындагы сүзләр йөрде. Икенчедән, декабрь башында ярдәмче итеп билгеләнгәч, Билалетдинов үзе дә артык зур планнар белән янмавын әйтте. «Эшсезлектән арыдым», – диде журналистлар белән сөйләшкәндә, шаярырга тырышты, артык зур планнар белән янмавын әйтте. Хәзер исә барысы да җитди булачак. «Әлеге карар җиңел кабул ителмәде. Баштарак планнар башка иде, әмма хәлләр мине шундый адымга барырга этәрде. Мин командага да, аның бүгенге хәленә дә битараф кала алмыйм. Ярдәм итә алырмын, уенын яхшыртырбыз һәм клуб алдындагы бурычны үтәрбез дип өметләнәм. Җиңел түгел, әмма үтәрлек һәм көчебез җитәрлек. Ул максатка тырышлык ярдәмендә ирешәчәкбез», – ди баш тренер.

Зиннәтулла Билалетдинов «Ак барс»та баш тренер вазыйфасына билгеләнәсен әле Олег Знарок килгәнче үк фаразлаучылар булды. Әмма Казан клубы башка кешене сайлады. Дөрес, Билалетдинов та кайтты, тик аңа башка эш таптылар. Олег Знарок командасы җиңелгән саен, таныш исемне ешрак кабатладылар. Ахыр чиктә юраган юш килде һәм Билалетдинов «Ак барс» белән өченче мәртәбә килешү төзеде. Беренчесе 2004 елда булган иде. Меңьеллык алдыннан, аны «йолдыз»лар тупланган командага, чемпионат башланып, бер ай узгач, Владимир Вуйтек урынына остаз итеп билгеләделәр. Дөрес, ул сезон уңышсызлык белән тәмамланды, ә чемпион исемен 2006 елда яуладылар. Соңрак «Ак барс» рәттән ике мәртәбә Гагарин Кубогын яулады. Сочи Олимпиадасы алдыннан Зиннәтулла Билалетдиновны Россия җыелма командасына баш тренер итеп алдылар. Ул үзе Казаннан китәргә ризалашмады, ә мәсьәләне Владимир Путин дәрәҗәсендә хәл иттеләр. 2011 елгы турнирның ничек тәмамланганын барыбыз да яхшы хәтерли. Сочидан ул туры Казанга кайтты. Танылган тренерны сезон ахырына кадәр генераль менеджер һәм клуб вице-президенты итеп билгеләделәр. Ә соңрак ул янә үзенең төп эшенә алынды. 2018 елгы җиңүне 4 ел көтәргә туры килде.

Бу юлы ничек булыр? Белгечләр беравыздан аның кайтуы файдага буласын, командада тәртип урнашасын, җиңүләр яуланасын әйтә. Моңа беркем дә шикләнми. Әмма дүртенче тапкыр Гагарин Кубогын оту өчен бу гына җитәрме? Кешедән калганны төзәтүгә караганда, үзеңә яңадан төзү кулайрак. Тик бу юлы төзелеш башларга инде вакыт калмады. Зиннәтулла Билалетдиновның ниләр эшләргә өлгергәнен яз көне күрәчәкбез. Аңа кадәр исә күңелсез булмаячак.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

ҮЗЕБЕЗНЕҢ КЫШ БАБАЙ

Казанда яшәүче һәр өч әтинең берсенә – Кыш бабай, һәр өч әнинең берсенә Кар кызы булып киенергә туры килгән. «SuperJob» хезмәте уздырган сораштыру нәтиҗәләре әнә шул хакта сөйли. Казанда яшәүче ир-егетләрнең 33 проценты Кыш бабай ролен балалары өчен уйнаган. 19 проценты бу рольне өйдә яки кунакта, ә 14 проценты балалар бакчасында яки мәктәптә башкарган. Сирәк булса да (сораштыруда катнашучы хатын-кызларның 3 проценты), Кыш бабай булып әниләргә дә киенергә туры килгән. Ә Кар кызы ролен бер тапкыр булса да һәр өченче әни башкарган. 22 проценты – өйдә, 10 проценты – күбрәк кеше җыелган җирдә. Казан халкы арасында, балалары булмаса да, башкаларга бәйрәм бүләк итүчеләр бар. Кыш бабай киемен сораштыруда катнашкан ир-атларның – 22 , хатын-кызларның 6 проценты кигән. Ә Кар кызы булу тәҗрибәсе гүзәл затларның 18 процентында бар. Ир-атларга исә бу рольне башкарырга туры килмәгән.

Чәчкаб Әлмәндәре

Кайбыч районы Иске Чәчкаб авылында яшәүче Бөек Ватан сугышы ветераны, 102 яшьлек Зиннәтулла бабайны «Чәчкаб Әлмәндәре» дип йөртәләр. Чыннан да, охшаган шул ул Әлмәндәр картка. Ачык йөзле, җор сүзле, зарлану дигән нәрсәне белмәс. 95 яшьлек юбилее алдыннан рәхәтләнеп сөйләшеп утырган идек. 100 яшьлегендә, пандемия сәбәпле, телефон аша гына хәл белешергә туры килде.

Бу юлы да кулга каләм алуымның сәбәбе бар. Эш болай булды. Зиннәтулла бабай гомере буена «Ватаным Татарстан»ны кулыннан төшермәгән. Хәзер дә, бер хәрефен дә калдырмыйча укып барам, ди. Тәнкыйтьләргә дә күп сорап тормый ул, мактап та ала. Бу юлы исә хата тапкан. Бервакыт газетага язар өчен без республикада яшәүче иң өлкән яшьтәге ир-ат белән хатын-кызны эзләгән идек. Рәсми төстә килгән җавап иде инде ул югыйсә. Әмма, нишләптер, андагы ир-ат Зиннәтулла абыйдан бер яшькә кечерәк булып чыккан.

– Күптән түгел генә чирләп киткән иде, – ди бу җәһәттән район башлыгы урынбасары Рамис Хәялиев. – Казанга 7 нче хастаханәгә озатканда бик моңсуланды. Хәтта: «Башка сезне күреп булмас инде», – дигән сүзләр әйтте. Сихәтләнде, шөкер. Матур гына әйләнеп кайтты. Хәлен белергә кергән идем. Шунда сөйләде. Мине онытканнар, ахры, дип кет-кет көлеп ята үзе.

Көлеп ятуы тагын бер «югалу»га бәйле Зиннәтулла бабайның. Бу хакта да искә алырга ярата ул.

– Бөек Ватан сугышы минем өчен Ржев шәһәрендә башланды. Курск дугасы, Белгород, Харьков шәһәрләрен азат итүдә катнаштым. Каты яралангач, Харьковтагы госпитальдә биш ай дәваландым. Аннары Уфага җибәрделәр. Кирәк бит, бәхеткәдер инде, Казаннан килгән хирург эләкте. Операциядән соң: «Аякларыңа энә белән төрткәч, азрак сизә башладың. Димәк, һичшиксез, аякка басачаксың, хәрәкәтлән. Хәрәкәттә – бәрәкәт», – диде. Ике шәфкать туташы мине култыклап, көн саен икенче каттан өченче катка алып менә, алып төшә башлады. Бераздан, таякка таянып, акрын гына йөри башладым. Бүгенгедәй хәтеремдә: 1944 елның 24 гыйнварында поезд белән Коләңгы станциясенә кайтып төштем. Мине ул вакытта алты айга өйгә җибәргәннәр иде. Вакыты җиткәч, хәрби комиссариатка бардым. Усанов дигән хирург бер айсыз юлга чыкмаска кушты. Яралар төзәлеп бетмәгән иде чөнки. «Үзебез чакырырбыз», – дип калган хәрби комиссар үзе юкка чыкты. Шулай яши торгач, сугыш та тәмамланды. Комиссар: «Син кая югалдың?» – дип башта сүкте, аннан гафу үтенде. Баксаң, минем документлар тутырылган папка юкка чыккан булган икән. Сугыш беткәч кенә каяндыр килеп чыккан. Хирург Усанов минем кабат сугышка китүемне бер айга кичектермәсә, белмим, минем язмышым ни булып бетәр иде. Хәзер уйлап ятам инде. Бәлки, үземә барырга кирәк булгандыр. Тик ул вакытта, чыннан да, сәламәтлегем нык какшаган иде шул. Көчем җитмәгән, күрәсең.

Көч дигәннән, Зиннәтулла бабай матур гына үз тормышын үзе күреп яшә әле. Хәләле Асиянең вафатына да 18 ел үткән инде. Өстәвенә ике баласының үлемен дә кичерә ул. Бер улы Шәүкәт – Америкада. Яшел Үзәндә яшәүче улы Илдус янына китүдән баш тарта. «Шәһәр фатиры төрмә кебек», – дигән сүзләр әйтә. «Подъезд төбенә чыгып утырсаң, телефоннан күзләреңне дә алмый үтеп китәләр. Монда, ичмасам, ерактан килеп исәнләшәләр», – ди. Ә туган җир туфрагына нык басып йөри әле ул. Сайлау вакытын әле дә кызык итеп искә алалар Кайбычта. Тартма белән өенә килгән булганнар аның. «Президент кадәр Президентны өйдә сайлау минем кебек егетләргә бер дә дөрес булмас», – дип, мәдәният йортына үзе барган. Казан каймасын төзүгә хөрмәтенә салынган һәйкәлнең ачылышына да барып кайткан. Ничек бармасын инде, сугышка киткәнче, ул анда үзе дә катнашкан бит.

Аның Кайбычта, Апаста финансист булып эшләгән елларын да хөрмәт белән искә алалар. 100 яшьлек юбилее уңаеннан Татарстанның финанс министры Радик Гайзатуллин да үз бүләген тапшырган. Рухи яктан да көчле ул Зиннәтулла бабай. Пенсиягә чыккач, дин юлына баса, авылның имамы була. Өлкәннәр өчен дә, балалар, яшьләр өчен дә әлегә кадәр өлге булып яши. Мондый кешене ничек онытасың ди инде?!

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Язучы фикере

Могҗиза

Марат КӘБИРОВ

Яңа елдан могҗиза көтү, теләкләр теләү гадәте бар бит инде. Үзеңә кирәкле нәрсәләрне Кыш бабайдан сорыйсың, ул сиңа шуны алып килмичә калмый. Кечкенә вакытымда мин дә күп әйбер сорадым. Кеше кулында күреп тәмләп карыйсы килгән ризыклар да, матур киемнәр дә, хәтта гармун белән вилсәпит тә сорадым. Бирмәде.

Бер мәлне теләгән нәрсәңне телдән генә сорарга түгел, ә кәгазьгә язып чыршы астына куярга кирәклеген төшендем. Һәм матур хәрефләр белән чаңгы сорап язган хатымны кулдан ясалган конвертка салып, авыл клубы алдындагы чыршы астына куйдым. Яңа ел җиткәнен ике-өч көн буена түземсезлек белән көтеп алдым. Ул вакытта мәктәп укучыларын өлкәннәр бәйрәменә кертмиләр, кич йөргәнне күрсәләр, тиргәшәләр иде. Тик мин, җаен табып, сәгать уникене сукканнан соң, теге чыршы янына барып бастым.

Анда бернинди дә чаңгы күренмәде. Мин, бәлки, бераз читкәрәк куеп киткәндер дип, тирә-якны да караштырып чыктым. Юк. Бәлки, өлгерә алмый калгандыр. Минем кебек малайлар күп бит инде ул, барысына да бүләк таратып йөри башласа... Болай уйлавыма чыршы төбендәге хатның юкка чыгуы да сәбәпче иде бугай. Димәк, Кыш бабай алган бит инде аны. Укыган. Димәк, ул миңа сораганымны алып киләчәк. Мин иртән торгач та, көндез дә, караңгы төшкәч тә, берәүгә дә әйтмичә генә, теге чыршы янынан урап кайтырга гадәтләндем. Булмады. Тик барыбер өмет өзмәдем. Аның сораган нәрсәмне бүләк итәчәгенә ышанычым сүрелмәде. Бар күңелем белән Кыш бабайдан могҗиза көттем. Башкача була да алмагандыр инде... Кыш бабай белән могҗизадан башка мине чаңгылы итә алырлык көч юк иде...

Ә көннәрнең берендә теге чыршы төбендә бер пар чаңгы ята иде. Мин өнсез булдым. Беркадәр катып торгач, чаңгыны бер-бер артлы кулга алып сыпырып карадым. Шәп! Өр-яңа! Пластиктан ясалган! Мондый чаңгы белән теләсә нинди көнне шуарга була! Өстәвенә бер читтәрәк таякларын да калдырган. Әйттем бит! Кыш бабай беркайчан да алдашмый ул. Хатыңны укыган икән, сораган нәрсәңне дә бүләк итә. Вакытында өлгерә алмаса, соңлабрак китерә. Сүз итеп сөйләп торасы бармыни, менә бит бөтен дәлиле күз алдында! Рәхмәт хисләреннән юешләнә башлаган керфекләрне лепелдәтеп, урам читендәге чаңгы юлына бастым. Бу оҗмах ишеге аша узуга тиң иде. Мин шулкадәр бәхетле идем. Мин Кыш бабайга да, Яңа елның тылсым икәненә дә берсүзсез ышана идем.

Соңрак бу чаңгының завклуб малае Айратныкы икәне ачыклангач, аз гына кыенрак булды инде. Чөнки мин Кыш бабай бүләгенең артык соңламый килгәненә шулкадәр сөенгән идем. Ә бурлыкта гаепләп маташуларына артык ис китмәде. Үземнең урлашмаганлыгымны мин үзем беләм бит инде. Шул җитә. Ә Кыш бабайга булган ышаныч барыбер сүрелмәде. Чөнки алдагы берничә ел эчендә мин сәпитле дә, чаңгылы да булдым. Кыш бабай әйтмәсә, барлы-юклы хезмәт хакына әни үзе генә ала белмәс иде әле аларны...

Яңа елдан могҗиза көтү миндә әле дә бар. Ул ниндидер тылсым алып килер дә бөтен дөнья яктылыкка күмелер, кешеләр күңеленә нур иңәр, алар изге күңелле ихлас затларга әверелер, бер-берсенә тик яхшылык кына теләп яши башларлар сыман тоела. Яктылыктан, нурдан, яхшылыктан торган шушы дөньяга беркайчан да хәсрәт күләгәсе төшмәс, кешеләр гел елмаешып, шатлык өләшеп гомер итәр...

Шушы өмет ышанычка әйләнеп үз җанымны да балкытып җибәрә. Чөнки тирә-ягымда да шундый ук затлар, алар да минем кебек үк Яңа елга, яктылыктан гына торган яңа дөньяга керергә өметләнә һәм үз өметләреннән үзләре балкып йөри. Могҗиза көтү тормышны могҗизага әйләндерә. Яхшылыкка өмет тоту яктылыкка әйди. Шундый якты кешеләр дөньясына Яңа ел да канатланып килә. Без дә аңа балкып керәбез...

Шул балкышны саклый алсак икән...

БӘХЕТЛЕ БУЛАСЫҢ КИЛСӘ...

Шактый катлаулы 2022 лабиринтлары аша үтеп, сикәлтәле 2023 елга аяк басарга җыенабыз. Алда торган көннәр сынауларыннан беребез дә имин түгел, моны беләбез, шуңа күрә көндәлек шом яши, төрле вәсвәсәләр үтеп кереп, төшенкелеккә бирелдерергә тырыша. Әммә кеше гомере кыска, еллар бик ашкын һәм тиз үтәләр, аларны рәхәт һәм бәхетле итеп үткәрәсе килә.

Бәхетле яшәүнең формуласын исә Козьма Прутков (өч язучының уртак псевдонимы бу) бик кыска гына итеп әйтеп бирә: «Бәхетле буласың килсә, бул!» – ди. Кыска булса да, шактый катлаулы формула бу, чишелешен тапмасаң, теләсәң дә, бәхетле яши алмыйсың. Чишелешен таптыңмы, тормышың үзгәрә: хәсрәтләр кими, шатлыклар арта.

Безне бәхетсез итеп тоярга мәҗбүр иткән нәрсәләрнең беренчесе – нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәнен адәм баласының үз акылы белән аңлый алмавы. Аллаһы Тәгалә бу хакта (мәгънәсе): «Сезгә нәрсә файдалы, нәрсә зарарлы икәнлекне Аллаһ белә, әмма сез белмисез», – ди (Коръән, «Бәкарә» сүрәсе, 216 нчы аять). Бу аять аңлатмасын калын китап язып аңлатып булыр иде, бәлки, әмма безнең андый мөмкинлегебез юк, шуңа күрә иман китерәбез һәм шикләнмичә кабул итәбез. Һәр кеше үз тормышын тирән анализлап караса, төшенә ала: нәфесебез яратмаган авырлыклар гадәттә безнең өчен файдага. Тынга капланган каршы искән җил очраклы исми, яу кырында очкан бер генә очраклы пуля да юк, арттан килеп пычак кадаучылар аны очраклы рәвештә кадамый – барысы да хикмәт иясе Аллаһның тәкъдире белән төгәл итеп һәм үлчәп язылган. Авырлыклар я җәза, я сынау булып киләләр. Җәзасы чистарта, сынавы (уңышлы үтә алган очракта) адәм баласын югарырак баскычка күтәрә. Авырлыклар белән сынаганда, Галәмнәрнең Хуҗасы безне ярдәмсез калдырмый, проблемаларны чишүнең оптималь юлларын күрсәтә, кемнәр шуларны файдалана – оталар, кире кагучылар чарасыз кала.

Әйдәгез, безгә бу дөньяда бирелгән кыйммәтле нәрсәләрне барлыйк әле. «Вакыт, кире кайтмаска дип тиз агучан вакыт – кешенең иң кыйммәтле байлыгы, һәм аны җилгә очыру – исраф итүнең иң начар формасы», – ди инглиз язучысы Сомерсет Моэм. Атаклы мөселман галиме ибн Баз: «Вакыт ул – тормыш. Кем вакытын югалтты, тормышын югалтты. Ә кем тормышын югалтты, ул үкенәчәк, әмма ул үкенү аңа файда бирмәячәк», – ди. Бик тирән фәлсәфә салынган бу юлларга. Безнең татарда да шундый гыйбарә бар бит: «Заяга үткән гомер бигрәк җәл». Вакытны саклау – аны файдалы нәрсәләр белән үткәрү, аны югалту – файдасыз нәрсәләргә сарыф итү. Адәм баласы ике файдалы нәрсәне туктаусыз чиратлаштырып яшәгәндә генә тулы тормышта гомер кичерә: бу дөнья өчен файдалы гамәлләр кылу, ахирәт өчен файдалы эшләр белән мәшгуль булу. Кул кушырып утыру (бигрәк тә авырлыклар алдында) яисә даими кәеф-сафа корып яшәргә тырышу вакытны югалтуга китерә һәм стресс һәм депрессия белән җәзалану котылгысызга әйләнә.

Миңа Эпикурның бер цитатасы ошый: «Һәрвакыт иҗтиһад ит (эшлә). Һәрвакыт ярат. Кешеләрдән рәхмәт көтмә, рәхмәт белдермәсәләр, күңелсезләнмә. Нәфрәт урынына – нәсыйхәт, җирәнеп карау урынына – елмаю. Кычытканнан җеп тукы, әремнән дару ясa. Егылганнарны күтәрү өчен генә иел. Үз-үзеңне яратудан өстенрәк акылга ия бул. Һәр кич үзеңнән сора: нинди яхшылык эшләдең?» Яшәүнең менә шул ысулын кабул иткәндә, Аллаһ теләсә, без бәхетле булуга таба зур адымнар атлый алырбыз.

Бәхетне җиңел тормыш дип атарга ярамый, әлбәттә. Киресенчә, җиңел тормыш – стресслар чыганагы ул. Бәхет гармоны киртәләр аша үтеп, җиңүгә ирешкәндә генә эшләнә һәм җанга-тәнгә ләззәт тарала. Әммә килешик: авырлыклар берсе өстенә икенчесе ишелеп килә башласа, шулай ук бер дә рәхәт түгел. Бу очракта нишләргә? Гафу итегез, бераз сәеррәк формула тәкъдим итәм, ләкин аны мин уйлап чыгармадым. Бу формула, чынлыкта, исламнан, әмма аны хәтта күп кенә имансызлар да бер төшенеп алсалар файдаланалар. Бүген иртән интернетны ачтым да, мәсәлән, «Если тебе плохо – начинай благодарить», – дигән язмага юлыктым. Сүз югалтканнарга көенүдән туктап, үзеңдә булганнарга шөкер итә башлау турында бара. Авыру булсаң да, тәнең яши, сулый – шөкер итәсең. Куркыныч тоясың икән, йөрәгеңнең һәм җаныңның тою хисен югалтмавына шөкер ит. Арттан пычак кадаучылар чиратка тезелгән икән, алар сине җиңәргә һәм алга барырга өйрәтәләр, шуңа шөкер ит. Сиңа яхшы икән, шулай ук шөкер ит. Бәхетең

vk.com

артканын тойсаң, шөкерне ташлама. Болар барысы да – Аллаһның сиңа бүләк итеп тәкъдиргә язылган нигъмәтләре, шуны онытмыйсың икән, депрессия синең йөрәктә урын тапмаячак.

Аеруча көчле шәхесләр хәтта сынауларның күплегенә дә шөкер итәләр. Тарлыкта да, киңлектә дә шөкер итүчеләр хисапсыз җәннәткә кертелә, әмма андыйлар аз була. Без андый ук түгел, шуңа күрә үзебезгә бирелгән нигъмәтләргә шөкер итәбез һәм югалтулардан зарланмыйбыз. Зарлану – шөкер итүнең киресе инде ул. Ул – тыелган. Шөкер итмәүнең бер чагылышы – көнчелек. Башкалар кулында булганга кайгыру кешене котылгысыз рәвештә стрессларга сала. Аллаһы Тәгалә бу хакта кыска гына итеп (мәгънәсе): «Әгәр нигъмәтләремә шөкер итсәгез, нигъмәтемне сезгә арттырырмын, әгәр көферлек кылсагыз, минем газабым каты», – ди («Ибраһим» сүрәсе, 7 нче аять). Тормыш авырлыкларыннан зарланып, стресска бирелү – Аллаһ газабының беренче этабы, бу дөньядагысы. Булганга шөкер итү үзе үк бәхет гармоны эшләнә башлауга китерә, чөнки организм шундый итеп корылган: канәгатьлек рәхәтлек кичерүгә илтә торган гармоннар эшләүгә хезмәт итә.

Аллаһның җәзасыннан һәм газабыннан котылуның тагын бер ысулы – гөнаһлар өчен кичерү сорау, тәүбә итү. Даими рәвештә истигъфар кылучылар (әстәгъфируллаһ дип, мәсәлән) газаптан ике дөньяда да имин булалар. Минем эшсез калган мөселманнарның берничә көн дәвамында кичерү сораганнан соң бик яхшы эш табулары турында сөйләгәннәрен ишеткәнем бар. Бу гаҗәп түгел, чөнки Аллаһның вәгъдәсе шундый. «Әнфәл» сүрәсенең 33 нче аятендә Аллаһы Тәгалә гафу итүне сорап торганда, имансызларны да газапка тартмаячагын вәгъдә итә. Аллаһ – вәгъдәсен үтәүче. Аллаһның барлык матди кризислардан алып чыгарга биргән вәгъдәсе дә истигъфар белән бәйләнгән (мәгънәсе): «... сезгә мал белән ярдәм итәр һәм балалар биреп куәтләндерер, дәхи җимеш үстерә торган бакчалар һәм елгалар бирер» («Нух» сүрәсе, 12 нче аять). Менә карагыз, бүгенге глобаль кризис нидән гыйбарәт: финанс куыкларында мал югала, бар илләрне демографик кризис биләп алды, йөзләгән еллар буе шаулап аккан зур елгалар саега... Аллаһы Тәгалә менә шул афәтләрдән безне коткару өчен бер генә шарт куя: тәүбә итәргә. Алтын гасырның төп шарты шул.

Бәхетле тормышка илтә торган тагын бер ысул бар – үзеңә зыян салучыларны кичерергә өйрәнү, үч сакламау. Галәмнәрнең Хуҗасы тигез күләмдә үч алырга да рөхсәт итә итүен, әмма кичерә белүчеләрне өстенрәк куя. «Бөек өлеш (бәхет) ияләре» дип атый. Гафу итеп, зур уңышка һәм бәхеткә ирешү турында мөселман булмаган авторларның әллә ничә китабы бар. Козьма Прутков әйткәнчә, бәхетле булырга телибез икән, Аллаһ өйрәткәннәрне үтәргә һәм йөрәк белән шөкер итәргә, йөрәк белән кичерү сорарга, йөрәк белән гафу итәргә өйрәнергә туры киләчәк. Боларга ирешү өчен үзеңне бик нык күнектерергә, хисләрне контрольдә алырга өйрәнергә кирәк. Башка юл юк. Хәсрәтле, кайгылы юллар гына бар.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Илдар Мөхәммәтҗанов

КАДЕРЕ АРТЫР БЕТКӘЧ

2023 ЕЛГА ФИНАНС ФАРАЗЫ

Узып баручы ел Россия икътисадына гына түгел, дөнья икътисадына да шактый йогынты ясаган вакыйгаларга бай булды. Алда ни көтәргә? Бигрәк тә акчаны учка йомарлап, «Нишләргә?» дигән сорау белән көн иткәндә. Шәхси керемнәр һәм тормыш итү өчен кирәкле товар-хезмәтләр өчен бәяләргә бәйле вазгыять аеруча күңелне кытыклап тора. 2023 елның нинди буласын төгәл әйтә алмасак та, финанс халәтебезне фаразлап карыйк. Бу юнәлештә күрер күзгә азмы-күпме барыбер нидер аңлашыла бит инде.

Өмет

Россиянең Икътисадый үсеш министрлыгы йөрәкләрдә өмет чаткысын кабызырга тырыша. 2023 елга оптимистик фаразлар да китерә ул. Әйтик, рәсми мәгълүматлар буенча, халыкның кереме – 1,6 процентка, реаль хезмәт хакы 2,6 процентка артырга тиеш.

Халык та ышана моңа. «Работа.ру» һәм «Подработка» хезмәтләре оештырган сораштыру нәтиҗәләре шуны раслый. Ил халкының 59 проценты киләсе елда кереме артыр дип ышана икән. 31 проценты хезмәт хакы артачак дип саный. 28 проценты, өстәмә керем чыганагы килеп чыкмасмы, ди.

Мондый кәефкә сәбәпләр дә юк түгел. Хезмәт базарындагы хәлгә күз салу да җитә: катлаулы халыкара вазгыятькә карамастан, эшсезлек буенча күрсәткечнең түбән һәм эшлим дигән кешеләргә ихтыяҗ барлыгын күрәбез.

Моңа өстәп яшәү минимумының, пенсия күләменең артуы, даими пособие барлыкка килүе дә керем дәрәҗәсенең артуына өмет уятырга сәбәпче. Хөкүмәтнең «2023 һәм 2024–2025 еллар чорына бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре» дигән документында да халыкның кереме 1,5 трлн сумга артыр дигән өметле сүзләр язылган.

Бер караганда, артык әйбәт тә яши башламабыз, бөлгенлеккә дә төшмәбез. Кем әйтмешли, вакыт күрсәтер монысын. Әллә ни озак көтәсе калмады бит инде.

Фараз

Финанс белгече Ләйсән Харисовадан: «2023 елда матди хәлебез нинди булыр?» – дип сораштык.

Икътисадка карап, киләчәккә фаразлар бирәбез, дисәк, алда әле җиңеллек көтелми. Вазгыятьнең нинди икәнен күреп торабыз. Махсус хәрби операция дәвам итә. Өстәвенә санкцияләр дә бар. Шуңа күрә җиңел сулап була димәс идем. Әлбәттә, республика Президенты элемтәләрне барларга тырыша. Әмма авырлыклар барыбер сизелә. Гомумән, махсус операция тәмамланмыйча бернинди дә үзгәреш көтәргә кирәкми. Үзебезнең көнкүрешебезне генә алыйк. Читтән витаминнар, кием-салым кайтарта идек. Хәзер аңа да юллар ябылды. Димәк, без башка илләр аша кайтартырга тиеш булабыз, ә бу кыйммәткәрәк тә төшә. Кеше кесәсендә сизелә бу. Икътисадка нефть тә, газ да тәэсир итә. Европада хәзер газ белән проблемалар. Бездән дә сатып аласылары килми, газ да кирәк.

Инфляциягә килгәндә, аның реаль һәм рәсми дигәне бар. Кесәбезгә карап инфляцияне чамаларга мөмкин. Рәсми дигәне 6–7 процент булса да, аны ике тапкыр арттырсак, реаль инфляция күрсәткече килеп чыгачак.

Бөтен нәрсәнең бәясе арта. Читтән кайтартылган, күнегелгән нәрсәләрдән файдаланасы килә бит. Әлбәттә, аларга алмаш табарга тырышалар. Ләкин әле һаман да тукымасын, башка чималын бүтән ил, шәһәрләрдән кайтарталар. Ул бәягә тәэсир итә.

Икенчел торак базарында бәя гел уйный. «Вторичка»га ихтыяҗ гел бар дип әйтергә була. Булган фатирларын сатучылар күп булды. Милекне чит илдән сатып алучылар бар. Аңа «запас аэродром» буларак карыйлар. Бу инде үзебезнең илдән акча чыга дияргә дә бер сәбәп. Акчасы булган кеше аны нишләтәсен үзе хәл итә инде. Әйтик, яшәргә урыны булмаган кешеләр «вторичка»дан аз гына очсызрак бәягә фатир сатып алырга мөмкин. Яңа төзелә торган йортларда фатирлар кыйммәтрәк.

Яңа ел чорында акча күп китә. Шуңа күрә, бүләк алабызмы, кибеткә керәбезме, табын корабызмы – алдан исемлек әзерләргә кирәк. Чыгымнарны киметү өчен чагыштыру ысулын кулланырга кирәк. Хәзер махсус мобиль кушымталар да бар моның өчен. Үзеңә кертем буларак нидер эшләргә телисез икән (белем алу, инвестицияләр), кредит алырга була. Әмма ихтыяҗ булмаган нәрсәләр өчен түгел.

Күп кенә банклар хәзер кешбэк дигән программа тәкъдим итә. Аз булса да, акча кайтару өчен бу да яхшы мөмкинлек.

Елына карап бәялә

Җиңел булмады. Календарьның соңгы битен әйләндергәндә, ел саен шул сүзләрне кабатлыйбыз бугай без. Ихластан сөендерде дә, бәгырьләрне телгәләп көендерде дә үткәндә тарих булып калачак 365 көн. Татарстан өчен бу ел нинди вакыйгалар алып килде соң?

•2022 елның 24 февралендә Россия Президенты Владимир Путин Украинада махсус хәрби операция башлануын хәбәр итте. 2022 елның 21 сентябрендә өлешчә мобилизация игълан ителде.

•2022 ел республикада Цифрлаштыру елы дип игълан ителде. Шушы ел кысасында 100дән артык чара оештырылды. Моннан тыш Бәшир Рәмиев исемендәге яңа IT парк сафка басты. Цифрлаштыру елында Казанда Kazan digital week, Digital Innopolis Days кебек халыкара чаралар, тарихта беренче мәртәбә узачак «Киләчәк уеннары»на әзерлек ярышлары узды. Цифрлы трансформация юнәлешендә Татарстан алдынгылыкка чыкты.

•Татарстан зур халыкара чаралар уздыру мәйданчыгы булудан туктамады. Халыкара төзелеш чемпионаты, Халыкара Татарстан нефть һәм газ химиясе форумы, Халыкара энергетика форумы, «Россия – Ислам дөньясы» икътисадый саммиты, Машина төзелеше кластер-форумы кебек ил һәм республика өчен әһәмиятле очрашу, тәҗрибә уртаклашу чаралары Татарстан башкаласында гөрләде.

•Татарстан Президентының чит илләргә һәм күрше төбәкләргә сәфәрләре дә күп булды. Төп игътибар – Көнчыгышка, мөселман илләренә. Рөстәм Миңнехановның Төркия, Бәһрәйн, Казахстан, Иран, Катар, Үзбәкстан, Азәрбайҗан кебек илләргә эшлекле сәфәрләре булды.

•Федераль дәрәҗәдә Идел буе Болгарында ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп үттек.

•20 майда Җәмигъ мәчетенә нигез ташы салынды.

•Республика башкаласы Казан быел «Ислам хезмәттәшлеге оешмасының Яшьләр башкаласы» дигән мәртәбәле исемне йөртте. Глобаль яшьләр саммиты, Халыкара фәнни конгресс узды, Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең киберспорт буенча чемпионаты оештырылды.

•Бөтендөнья татар конгрессының VIII съезды узды, конгресс оештырылуга 30 ел тулды.

•Казанда ЮНЕСКО конвенциясенең 50 еллыгына багышланган халыкара форум узды. Тарихи һәм рухи кыйммәтләр турында фикер алышырга Татарстан башкаласына БДБ, Азия, Африка, Латин Америкасы илләре вәкилләре килде.

•20 октябрьдә Татарстан Президенты Дәүләт Советына Юллама белән чыгыш ясады. Асылда, республика җитәкчесе алга таба ничек эшләячәгебезне һәм яшәячәгебезне билгеләде.

•Җәй, көз айларында «Дуслык уеннары» ярышлары узды.

•«Рубин» командасы үз тарихында тәүге мәртәбә премьер-лигадан төшеп калды. Сезон уртасында баш тренер Леонид Слуцкий эшеннән китте. «Ак барс» та җанатарларын сөендерә алмый. Командага көчле уенчылар тупланса да, нәтиҗә булмагач, декабрь башында баш тренер Олег Знарок отставкага китте. Аның урынына Зиннәтулла Билалетдиновны куйдылар.

«Татар-информ»

2022 ел – саннарда

Тулай төбәк продукты буенча – **7** нче урын.
Сәнәгать җитештерүе буенча – **6** нчы урын.
Авыл хуҗалыгы тармагы буенча – **7** нче урын.
Төзелеш тармагы буенча – **5** нче урын.
Төп капиталга инвестицияләр җәлеп итү буенча – **6** нчы урын.
Ваклап сату, кече һәм урта эшмәкәрләр саны буенча – **7** нче урын.
Сөт җитештерү буенча – **1** нче урын.
Ит җитештерү буенча – **6** нчы урын.
Идел буе федераль округында гомер озынлыгы буенча да, үлүчеләр санын киметү буенча да – **1** нче урын.
Юллар төзелешенә **194 млрд** сум акча тотылды.
Авыл хезмәтчәннәре рекорд куйды – **5 млн** тоннадан артык ашлык җыеп алынды.
3 млн 90 мең квадрат метр торак кулланышка тапшырылды.
Яңа **11** мәктәп, **5** балалар бакчасы төзелде.
Татарстанда яшәүчеләр саны **4 миллион**нан артты.
Федераль һәм республика программаларына **122 млрд** сум акча тотылды.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Куян нинди – елы шундыймы?

Әтнәдә яшәүче Искәндәр Галиев шәхси хуҗалыгында 150ләп куян тота. Аның озынколакларга булган мәхәббәте 5 нче сыйныфта укыганда бөреләнә. Ул чагында кырда бәрәңге җыйганда ул бер куян баласы тота. Читлек ясап, көтелмәгән куянны шунда урнаштыра, тик иртәнгә ул чыгып кача.

– Хуҗалыкта куян тоту теләге шуннан барлыкка килде, – дип искә алды ул. – Күрше авылдан куян баласы барып алдым да аларны үрчетә башладым. Итеннән ризыклар пешерсәк, тиреләрен тапшырып, азмы-күпме акча эшли идем. Мәктәпне тәмамлаганчы шөгыльләндем мин алар белән.

Шуннан соң шактый еллар дусларыннан аерылып торырга туры килә Искәндәр абыйга. Әтнәгә күченгәч, 16 ел элек дусты ана куян күтәреп килә.

– Суярга кызганыч, син үрчет әле аларны, диде дустым. Кире борып җибәрмәдем инде, тәҗрибәм дә бар бит. Берничә көннән үзем тиз генә ясап куйган кәгазь тартмада тугыз бала китерде. Шуннан бирле мин гел куяннар арасында, – дип елмая ул.

Әлеге вакытта куяннарның бер өлеше – читлектә, бер өлеше урамда бүлеп алынган махсус урында яши.

– Ак великан, күбәләк токымлылар авыруларга бирешмәүчән була. Алар табигый шартларда үсә. Авырулары булганнар үзләреннән-үзе кимеп тора. Миңа аларның авырлыклары мөһим түгел. Биш килограммлы бер куян тотканчы ике 2 килограммлы куян тотам мин. Иң мөһиме – табигый шартларда үсуләре. Куянга иң яхшы ризык – болын печәне, люцерна. Кыш буена ике төргәк үлән җитә аларга. Бакчаның яртысына – кәбестә, ярты өлешенә бәрәңге утыртам. Моннан тыш, арпа белән бодай кушып бирәм, кукуруз ашатам. Бер елдан соң гына җитлегә алар. Гадәттә, бер куяннан 2–2,5 кг ит чыга. Итләре бик йомшак, тәмле генә түгел, медицина ягыннан карагандa иң файдалысы да. Аллергиясе булган балалар өчен – иң шәп ит. Шулпасы, шашлыгы да тәмле була. Тик мин аларның берсен дә сатмыйм. Күбрәк күчтәнәч итеп бирәм, – ди Искәндәр абый.

Кыргый куяннар белән чагыштырганда, йортныкылар йон төсләрен алыштырмый. Бүген Искәндәр абыйның хуҗалыгында ак, кара, соры, аклы-каралы, аклы-сарылы, көл һәм башка төсләр яши. Бер анадан сигез төрле төстә бала туарга мөмкин икән. Холыклары да төрле.

– Урамда яши торганнары кыргыйрак, хәтта миннән дә куркалар. Араларында усал, әрсезләре, балаларын җәберләүчеләре, ашаучылар да очрады, тик аларын бетерергә тырышам. Шуңа күрә куяннар куркак кына була дип әйтү дөрес түгел. Йорт куяннары кырныкыннан бик нык аерыла. Алар салкынга һәм артык эссегә чыдам түгел, шуңа күрә бездә йорт куяннары табигый шартларда яши алмый. Куян елын аларның холыкларына гына карап берничек тә билгеләп булмый. Сәяси-икътисадый яктан киләсе ел узып баручысыннан җиңел булмас кебек тоела. Шуңа күрә үз хуҗалыгыңны булдыру начар түгел.

Шәхси хуҗалыкта тотарга уңайлы куян токымнары: калифорния, совет шиншилласы, ак великан, күбәләк. Алар тәрбия өчен нәзберек түгел, авыруларга бирешмәүчән.

КОЛАГЫ ОЗЫН, ТАБЫШЫ ЗУР

Дөньядагы иң зур куяннарны Актаныштa үрчетәләр. Фландер токымлы озынколакларның авырлыгы хәтта 12 килограммга кадәр җитә. Ничә айлык куянның ите иң тәмлесе санала? Ни өчен аларның колакларына кагылырга ярамый? Аларны күпләп үрчетүче Илнур Гыйләҗевтан әлеге үзенчәлекле хайваннарны тәрбияләү серләре белән кызыксындык.

Барысы да бүләк ителгән ике куяннан башланган. Ул вакытта Илнур мәктәптә генә укый әле. Әлеге хайваннар белән кызыксына башлар өчен шушы ике дусты булу җитә дә. Чаллыга укырга киргәч, аларны тәрбияләү нечкәлекләрен тагын да тирәнтенрәк өйрәнә башлый ул.

– Ферма төзергә акрынлап акча җыя башладым. Максатыма ирешү өчен машинамны да сатарга туры килде. Гигант куян үстерүчеләрне интернеттан эзләп табып, тәҗрибә уртаклашырга төрле төбәкләргә, шәһәрләргә бардым. Шулай ук күп мәгълүматны интернеттан һәм китаплардан эзләп таптым. Ферманы төзеп бетерેп, читлекләр ясадым. Беренче куяннарны Пензадан заказ белән кайтардым. Самарадан 6–7 сәгать машина багажнигында да алып кайткан чаклар булды. Алар ерак юлларны җиңел кичерә. Нәсел куяннарын 2500 сумга сатып алган идек, – диде ул.

Бүген инде Илнурның куян фермасы яхшы табыш китерә. Баштагы вакытта аларны иткә саткан. Бераздан Казандагы рестораннар белән хезмәттәшлекне ныгытып җибәргән. Илнур бүген ничә куяны барлыгын төгәл генә әйтә алмады, чөнки илле ана куяннан туган озынколакларның үскән берен сатып баралар икән. Ун ата куяны да бар.

– Тиз үрчиләр. Бер куян елга 60 бала китерә. Яңа туган куян баласы бармак буе гына була, тик алар тиз үсә һәм биш-алты айда өлгерә. Уртача 8–9 килограммлы куяннан 5–6 кг ит чыга. Ашатудан да тора, билгеле. Яхшы катнаш ризык, вакытында вакцина була икән, яхшы үсә алар. Тик һәр нәрсәнең үз вакыты булган кебек, монда да чиктән чыкмаска кирәк. Алты айдан соң куян авырая, мускуллары тыгызлана, ите катылана. Болар – әлеге токымга гына түгел, теләсә нинди куянга хас сыйфатлар, – ди ул.

Фермер әйтүенчә, фландер токымлы куяннар – иң тынычлары.

– Минем бик күп куян токымнары белән эшләп караганым булды. Калифорния, совет шиншилласы арасыннан иң тынычлары – шушылар. Алар иң аз хәрәкәтләнүчән һәм күп тәрбия сорамый торганнар. Ашыйлар да йоклыйлар, тик сәламәтлекләре буенча фландер токымлы куяннар – иң нәзберекләре. Чөнки алар безнең климатка яраклашмаган – җылы яраталар. Аларга даими рәвештә вакцина ясап торырга кирәк, – ди Илнур.

Тырыш егет сүзләре буенча, куян асрап, яхшы табыш алыйм, дисәң, нәселле куяннарны күпләп үрчетү отышлы.

– Куяннарга дөрес тәрбия күрсәтсәң, бер кыенлыгы да юк. Тик барысын да бик белеп, өйрәнеп эшләргә киңәш итәм. Мин инде хәзер вакцинаны да үзем салам, моның белән бер проблема да юк. Бер куянга вакцина ясату 350 сумга төшә. Ә ул елына 50–60 бала китерә. Әгәр бер озынколактан ким дигәндә кулга чиста 1000 сум алсак, димәк, бер ана куян елына 50–60 мең сум табыш китерә ала. Күпләп сатып җибәргәндә бер кг итне 450–500 сумнан алалар, – дип санап күрсәтте эшмәкәр.

Әлеге төр куяннарны ашатып тору да артык катлаулы булмавын әйтте Илнур, чөнки фермасында барысы да автоматлаштырылган. Ризык та, су да үз вакытында тагаракларга килеп тора икән.

– Иң мөһиме – вакцина, чисталык һәм җылылык. Түбән температурада кечкенә куяннар үләргә мөмкин, – ди ул. – Күпләр, куяннар чи бәрәңге, чөгендер, кәбестә, яшел үлән генә ашап тора, дип уйлый. Тик болар да саулыгына зыян салырга мөмкин. Куяннарның ашказаны нәзберек, ярамаган ризык ашатсаң, эчләре китә. Ә аны дәвалау бик авыр. Шуңа күрә нигездә катнаш азык, печән бирәм, ә яшелчәләр белән атнага бер-ике тапкыр сыйлау да җитә. Җәй көне дә гел сусыл азыкта гына торырга тиеш түгел алар. Сәламәт булсын дисәң, коры азык бирергә кирәк. Шулай ук куяннарны атнага бер тапкыр ашатмый тору да файдага.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Куяннар турында кызыклы фактлар

✸Куянның колаклары озын булса да, алардан күтәреп алырга, тотарга ярамый. Чөнки колак турысыннан кан тамырлары уза, аларга зыян килеп, колаклары имгәнергә мөмкин. Нәтиҗәдә авырлык җыюдан туктыйлар. Моннан тыш, җәен куяннар колакларын тәннәрен суытыр өчен файдалана. Колакларына зыян килсә, җәен – эссене, кышын суыкны бик авыр кичерә.

✸Куяннар хуҗасының исенә ияләшә, аны үз итәләр. Ләкин чит кеше керсә, тавышыннан, исеннән, киеменнән танып, куркалар. Шуңа күрә куяннар янына хушбуй сибеп керү тыела.

✸Куян тоткан җирдә песи, тычкан, тавыклар булырга тиеш түгел, чөнки алар төрле авыру йоктырырга мөмкин. Куяннарның бәбиле торган бүлекләренә дә чит кешене кертергә ярамый. Ул куянга зур стресс китерә. Нәтиҗәдә бәбиләрен ашарга, карамаска мөмкиннәр. Шуңа күрә куяннарны гел бер кеше генә караса яхшы.

✸Куяннарның күзләре яхшы күрә. Шулай да алар күп мәгълүматны ис тоемлау аша ала.

✸Бер анадан туган куян балаларын кушылдырырга ярамый, бу нәселдәнлеккә начар тәэсир итә.

✸Куяннарны каплатканда, ата территориясенә ана куянны кертсәң яхшырак. Ата куян үз территориясендә үзен иркенрәк хис итә. Җәй көне эссе булганда – төнлә каплату, ә кыш көне, киресенчә, көндез каплату уңышлы санала. Куянга, бәбиләсен өчен, 15 градус җылы җитә. Ул елына дүртбиш тапкыр бәбили, берьюлы җиде-сигез куян баласы тудыра.

✸Нәсел өчен калдыра торган куяннар күбрәк сөт имәргә, нык булырга тиеш.

Өмет



Фәнис ГАБСАБИРОВ (Баулы):
– Минем хуҗалыкта язын үрчетер өчен 15 куян калды. Бер куян уныш балага кадәр тудыра, шуңа күрә бик тиз үрчи алар. Киләсе елда яңа гаиләләр күбрәк булыр, ялгызлар парларын табар, дип уйлыйм. Гомумән, куяннар күңеләмә бик хуш килә минем. Алар тынычлык ярата. Шуңа күрә Куян елында дөньяга тынычлык килер, дип өметләнәм. Дөньялар тынычланып, ир-егетләр өйләренә, якыннары янына кайтсыннар иде инде.

ҮТКӘНДӘ КАЛСЫН

Наил МӘҺДИЕВ, Чаллы мэры:

– Узып баручы ел бөтен дөньяның ныклыгын сынады. Өлешчә мобилизация кешеләрне берләштерде. Өч ай эчендә Чаллыда яшәүчеләр хәрби операциягә киткәннәргә ярдәм итәр өчен 128 миллион сумнан артык акча җыйды. Хәрбиләрнең гаиләләренә ярдәм итү эшен дә безнең шәһәр беренчеләрдән булып башлады. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның өлешчә мобилизацияләнгән ир-атларның гаиләләренә ярдәм итәргә дигән карары чыккан көнне үк сабыйларны үз канатыбыз астына алдык. Әтиләре мобилизацияләнгән балалар бакчаларга йөргән, мәктәптә ашаган өчен түләүдән азат ителде. Транспортта йөрү, шәһәр яны лагерьларында ял иттерү, төрле спорт һәм башка түгәрәкләргә йөрту бушлай оештырылды. Хәрбиләр салым түләүдән дә азат ителде. Ирләре хәрби операциядә катнашкан хатын-кызларга, балалары тугач, 100 мең сум акчалата ярдәм бирелде. Бу гаиләләргә бөтенебез бергә, гади халык, оешма җитәкчеләре булышты. Алга таба карап яшәргә кирәк. Ир-атларыбыз әйләнеп кайтыр. Аларга тернәкләндерү чаралары да кирәк булыр. Без инде бу эшкә бүгеннән әзерләнәбез. Махсус шифаханә комплексы җиһазландырылды, белгечләр укыта башладык.

2023 елда шәһәребездә яңа йортлар сафка басар. Киләсе елга төзүчеләр алдына зур бурычлар куела. Йортлар янәшәсендә мәктәп тә, балалар бакчалары да төзеләчәк. Яр буйларын төзекләндерү эшләрен дәвам иттерәбез. Капиталь төзекләндерү, юллар төзелеше, тирә-якны яңарту эшләре дәвам иттереләчәк. Ил җитәкчеләре ярдәм итеп торганда, без алдыбызга куелган бурычларны үтәп чыга алачакбыз. Чаллы – илгә «КамАЗ» ясаучы шәһәр. Шуңа күрә ул бар яктан үрнәк, алдынгы булырга тиеш!

Гөлназ ШАКИРҖАНОВА, биш бала анасы:

– Мин бу елга рәхмәт кенә әйтәм. Иң мөһиме – якын кешеләрем исән-сау. Олы балаларым мәктәптә укый, өч игезәк улым бакчага йөри. Шуларга сөенеп, гомер узганын сизми дә калабыз инде. Быел бал булмас, дип тә борчылган идек. Карап торган шөгылең шул булгач, кайгырасың да инде. Шулкадәр уңышсыз калдык дип уйладык. Шөкер, балыбыз күп булды. Шуларны урнаштыра алдык. Безнең өчен анысы да зур бәхет. Ә инде күптән түгел мин бик дәрәҗәле исемгә лаек булдым. «Ана даны» медале белән бүләкләндем. Шуңа тап төшермичә, матур итеп яшәсәк иде, дим. Гаиләбез белән Балтач районының Куныр авылында яшибез. Мине авылның киләчәге дә бик борчый. Яшьләр шәһәргә китмәсен иде, дип телим. Балалар күп туып, авыл урамнары яңадан сабыйларның шат тавышына күмелсен иде. Һәр кеше үз гаиләсендә бәхетле яшәсен. Балалар әти-әни тигезлегендә үссен иде. Быел тынычлыкның кадере артты. Киләсе елда һәр йортта иминлек булып, сөенечле хәбәрләр ишетеп, берберебезне аңлап, яратып яшәсәк иде.

Әлфинә МАННАНОВА, ирен хәрби операциягә озаткан ханым:

– Ел әйбәт кенә башланса да, өлешчә мобилизация башлангач, тормышыбызның асты-өскә килде. Иремне махсус хәрби операциягә алып киттеләр. Гомерем буе ирем канаты астында яшәгәч, ялгызыма гына тормыш алып бару кыенлашты. Баштарак бик авыр булды. Нишләргә дә белмәдем. Туганнарым, якыннарым янәшәдә булды. Ике балама карап юандым. Без, олылар, илдәге хәлләрне аңласак та, балаларга әти кирәк. Аларга хәрби операция барганын берничек тә аңлатып булмый. Аларга әти кирәк! Иртән мәктәпкә барганда: «Әти кайчан кайта?» – дип бер сорыйлар, кичен тагын шул сүзне кабатлыйлар. Үземә бу ел сабак бирде. Янымда чакта иремнең кадерен белеп бетермәгәнмен икән. Хәзер мин тормышка тешем-тырнагым белән ябышып яшәргә өйрәндем. Ирем өйдә юк дип, кешедән ким-хур буласым килми. Балаларым да әтиләре юклыгын сизмәсен, дим. Бер генә теләк: мондагы ир-атлар бүтән беркая да китмәсен, киткәннәр гаиләләре янына исән-сау әйләнеп кайтсыннар иде.

Илсөя БӘДРЕТДИНОВА, Татарстанның атказанган артисты:

– Узып баручы ел эшкә бай булды. Шунысына шөкер. Әмма әзрәк сәламәтлек борчып, куркытып алды. Әле дә табибларга күренеп торырга диделәр. Ә тормыш дәвам итә. Сукранып, сыкрап утырыр чак түгел. Бер дигән төркемем бар. Аларның гаиләләре өчен сөенәм. Гастрольләрдә йөрсәк тә, ел саен берәр бала туып, артып торалар. Бер генә теләк – илләр тыныч булсын иде. Бу урында әбиемне искә төшерәм. Бигрәк зирәк булган инде ул. Без балачакта әни урамнан кайта да, фәләннең малае туган, дип сөенче ала. Әби күп сөйләшми, үз алдына бер-ике сүз генә әйтеп куя. Табигать сугышка әзерләнә, ди. Без аңламыйбыз. Малай туган саен, шул сүзне әйтте. Быел исә әбинең сандык өстендә, илләр тыныч булсын, сугыш афәтләре күрсәтмә, Ходаем, сәламәтлектән аерма, дип дисбесен тартуының мәгънәсен аңладык. Без хәзер фәләннең кыска итәк, ертык чалбар кигәнен оныттык инде. Дөнья үзенчә уйланырга башлады. Тормыштан вак-төяк әйберләр төшеп калды. Яшәүнең кадере артты. Буй җиткән улым да бар бит әле минем. Исән-имин генә булсын, дип телим. Укый, эшләп йөри. Егет үстерүче әниләр мине аңлыйдыр. Шуңа да сәламәтлек һәм күңел тынычлыгы кирәк. Башка нәрсәдән зарлана торган түгел. Газета укучыларга да бары тик изге теләкләремне юллыйм. Күңелдә йөрткән хыялым бар: үзем һәм татар эстрадасы хакында, дөресен сөйләп, үз акчама документаль фильм төшерәсем килә.

Газинур МОРАТ, Татарстанның халык шагыйре:

– 2022 санында «2ле»ләр күп. Елына да «2ле» куяр идем мин. Ил-көндәге вазгыять безнең иң авырткан җиргә – күңелгә каты кагылды. Бер классигыбыз әйтмешли, «Минем бәхетле булырга хакым юк, чөнки мин – язучы». Шатлыгы да булмады түгел анын. Ел ахырында, Ходай рәхмәте, Президентыбыз кулыннан шәрәфле бүләк кабул итеп алырга насыйп булды – «Татарстанның халык шагыйре» исеме бирелде. Иҗатчы тормышында бик сирәк була торган хәл-вакыйга, сөенеч бу. Татар әдәбияты өчен 2022 ел 2021 елгы уңышлар яктылыгында узды, миңа калса. 2021 елда бик зур әдәби конкурс уздырдык. Быел җиңгән әсәрләрнең барысы да дирлек «Казан утлары»нда басылып чыкты. Әлеге конкурс татар әдәбиятын алга этәрә торган әсәрләрне, авторларны ачыкларга ярдәм итте, дияр идем мин. Әсәрләр сан ягыннан гына түгел, сыйфат ягыннан үсеп киткән кебек булды. Инде менә 2023 елга аяк басабыз. Хәере белән килсен иде! Тәртибенә һич югы «3ле» куярлык булсын.

Энҗе ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф бүлеге башлыгы:

– Үтеп баручы ел яңа программалардагы уку планнарын күреп борчылудан башланган иде. Әмма әлеге проблеманы бергәләп уңай хәл иттек. Нәтиҗәдә туган тел укыту планнарында сакланды. Сөйләмгә өйрәтүгә юнәлтелгән дәреслекләр эшләнде, алар федераль исемлеккә кертелде. Дәреслекләргә нигезләнеп электрон ресурслар да эшләнде. Мәсәлән, татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү өчен «Сәлам» дәресләре һәм сайты, Фәннәр академиясе белгечләре тарафыннан язылган электрон дәреслекләр бар. Соңгы елларда татар телендә белем бирелүче 1 нче сыйныфлар саны арту сөендерә. Татар теле укытучыларының съезды, милли мәгариф буенча форум үткәрелде. Федераль дәрәҗәдә узган туган тел укытучыларының һөнәри бәйгесендә Казан укытучысы Зилә Габдинова лауреат булды.

Яңа елда, Педагог һәм остаз елы, Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы буларак, туган тел укытучыларының дәрәҗәсен күтәрү өчен нәтиҗәле чаралар уздырылыр, җәмәгатьчелектә милли мираска, туган тел өйрәнүгә бары уңай караш булыр дип ышанабыз.

Васил ГАРИФУЛЛИН, КФУның милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы мөдире:

– Елдан-ел арабыздан журналистиканың башында торган остазларыбыз китә. Быел Илдар абый Низамовны югалттык. Әмма тормыш дәвам итә. Алга таба эшләргә кирәк. Быел күп кенә студентларыбыз кызыл диплом белән укуларын тәмамлап, эшкә урнаштылар. Алар өчен дә сөенәбез. Димәк, татар журналистикасының киләчәге өметле. Үзем өчен дә быелның август аенда көтелмәгән, шатлыклы вакыйга булды. «Бәллүр каләм» бәйгесенең иң зур бүләген бирделәр. Гран-при иясенә тапшырылучы беренче машинаны Флорид Әгъзамов алган иде. Еллар узгач, мине дә зурладылар. Әмма мин аны шәхсән үземә дип кенә кабул итмәдем. Моны журналистика мәктәбенә 60 ел тулуга зур бүләк, остазларыбызның хезмәтенә дә зур бәя булды дип уйлыйм. Киләчәккә өметләр зурдан. Барысы да яхшы булсын иде дип телибез. Журналистларга бары тик яхшы хәбәрләр генә ирештерергә язсын!

Айрат ГАЛИМОВ, Минзәлә районының Аю авыл җирлеге башлыгы:

– Аю кебек, өндә генә качып ятмыйбыз, тырышып хезмәт итәбез. Киләсе елда башкарылачак эшләр турында җирлекнең генераль планын кабул иттек. Быел Аю авылында федераль программа буенча парк төзелде. Шунда ук инвестор ярдәме белән балалар мәйданчыгы урнаштырдык. Икенче елга паркны тагын да баетырга исәп. Мобилизацияләнгән егетләргә ярдәм итүчеләр күп булды. Китапханәчебез, авылның әби-апаларын җыеп, солдатларга оекбаш бәйләүне оештырды. Авыл җирлегендә 2400 баш сыерга исәпләнгән мегакомплекс төзелә. Эшләп китсә, 160лап белгеч кирәк булачак. Аларга йорт салу өчен 40–50 җир кишәрлеге билгеләдек. Юллар, күперләр төзү дә каралачак.

Рамил хәзрәт ЮНЫС, «Иске таш» мәчете имам-хатыйбы:

– Без – мөселман халкы. Еллар, фасыллар ул – Аллаһы Тәгаләнең мәхлукатлары. Шуңа күрә без – һәрбер көн, ел, ай, фасыллар белән канәгать булырга тиеш. Нинди генә вакыйгалар булмасын, без аның белән канәгать. Ник дигәндә, һәр вазгыять – адәм баласы өчен дәрес, үзенә күрә бер хикмәт чыганагы. Шуңа күрә без һәр елдан билгеле бер нәтиҗә алырга тиеш. Нинди хаталар җибәрдек? Нинди гамәлләрне дөрес кылмадык? Бу көннәрдә без шул рәвешле тормышыбызга билгеле бер анализ ясап, киләсе елда хаталарыбыз булмасын дип тырышып, хәерле планнар корырга тиеш. Илебез, көнебез, шәһәр-авылларыбыз, гомумән, Җир йөзендә яшәгән барча халыклар өчен дога кылыйк. Тыныч, имин еллар килсен, балаларны, оныкларыбызны исән-сау тәрбияләп үстерергә насыйп булсын, дип, хәерле, күтәренке рух белән иске елны озатып, Яңа елга аяк басарга язсын.

Вилдан ЗӘЙНУЛЛИН, умартачы (Биектау районының Сая авылы):

– Быел бал бик күп булды, әмма аны урнаштыру кыенлашты. Сатып бетереп булмый, ни өчен дигәндә, умартачылыкта – «тупик». Сату булмаса, әлеге тармак артка тәгәрәячәк. Шуңа күрә бу мәсьәләне дәүләт дәрәҗәсендә хәл итмичә булмый. Беренчедән, реклама, икенчедән, җитештерүне, умарталар санын киметү кирәк.

2 гыйнвар | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

14.35, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.00 «Сәйлән-2022» 0+
09.00 «Яңа татар җыры-2022». Рәшит Ваһапов исемендәге татар җыры бәйгесенең гала-концерты 6+
13.00 «Ялт-йолт». «Мунча ташы» эстрада театрының сатирик күңел ачу тапшыруы 12+
16.30 «Татарлар» 12+
17.00 «Чакыра юлларым». Мурат Гайсин концерты 6+
18.35 «Хуҗа Насретдин мәзәкләре» 12+
18.45 «Өмет йолдызы». Эльмира Кәлимуллина концерты 6+
20.00 «АЛМАШ» 12+
20.30 «МЕНӘ УЛ БӘХЕТ!» Телевизион музыкаль фильм 6+
22.00 «СТАРЫЙ НОВЫЙ ДОМ» 12+
23.45 «Яңа елны ТНВ белән каршылыйк!» (2021 ел) 6+
04.15 «Секреты татарской кухни». Екатерина Манько готовит чебуреки 12+
04.40 «Каравай». Первая профессиональная художница Татарстана 6+
05.05 «Секреты татарской кухни». Ансамбль «Злачное место» готовит хинкали 12+
05.30 «Каравай». Виртуоз-баянист Динар Бадрутдинов 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Фердинанд Саләхов турында телеочерк (субтитрлы) 6+
07.00 Г.Кариев. «АРТИСТ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
08.00 «АВЫЛ ЭТЕ АКБАЙ». Балалар өчен спектакль 6+
09.10 «ӨМЕТ ЙОЛДЫЗЫ». Эльмира Кәлимуллина концерты 6+
11.00 «Сәйлән» балалар телевизион фестивале 6+
12.05 «ЯҢА ЕЛДА МИНЕМ ГАИЛӘМ». Телефильм. Беренче серия 12+
13.00 Татарстанның халык артисты Зөфәр Хәйретдиновның юбилей концерты 6+
16.30 Т.Миңнуллин . «ЙӨРӘК МАЕМ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
19.00 «Яңа татар җыры». Гала-концерт 12+
22.00 «ЯҢА ЕЛДА МИНЕМ ГАИЛӘМ». Телефильм. Беренче серия 12+
22.40 «СИҢА КАЙТАМ» 12+
02.15 «Яңа елны ТНВ белән бергә каршылыйк!» Бәйрәм концерты 6+

1 КАНАЛ

05.15 Фильм «Карнавал» 0+
06.00 Новости
06.10 «Карнавал» 0+
08.00 Телеканал «Доброе утро»
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 «Жизнь своих» (S) 12+
11.10 «ПроУют» (S) 0+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» Новогодний выпуск 0+
13.25 «Повара на колесах». Полная версия 12+
14.30 Фильм-сказка «Морозко» 0+
16.05 Маколей Калкин в комедии «Один дома» 0+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 «Фантастика» (S) 12+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. Павел Прилучный. «МАЖОР». Новые серии (S) 16+
22.25 «Сегодня вечером» 16+
00.30 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

04.15 «Песни от всей души». Новогоднее шоу Андрея Малахова 12+
07.10 Владимир Машков, Евгений Миронов, Елена Лядова, Пётр Мамонов, Ирина Розанова, Сергей Чонишвили, Андрей Смоляков, Сергей Дьяченко, Владимир Гостюхин. «ПЕПЕЛ» 16+
09.00 Вести
09.35 «Пятеро на одного»
10.15 «Сто к одному». Телеигра
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.35 Владимир Машков, Сергей Маковецкий, Владимир Меньшов, Михаил Пореченков, Светлана Крючкова, Константин Лавроненко. «ЛИКВИДАЦИЯ» 16+
14.35 Местное время. Вести-Татарстан
14.50 Премьера. «Песня года».
18.00 «Песни от всей души». Вечернее шоу Андрея Малахова. 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Максим Аверин. «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
23.25 Максим Аверин, Нина Усатова, Анна Якунина, Александра Никифорова, Евгений Морозов, Яна Крайнова, Олег Масленников- Войтов, Алексей Коряков, Александра Каштанова, Михаил Богдасаров. «НЕВЕСТА КОМДИВА» 12+
01.25 Александр Галибин, Анна Ковальчук, Олег Басилашвили. «МАСТЕР И МАРГАРИТА» 16+
03.20 Елена Подкаминская, Кирилл Сафонов, Светлана Смирнова- Марцинкевич, Сергей Горобченко, Наталья Романычева. «ДРУГИЕ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Магия спорта» 12+
06.30 «Что по спорту? Кемерово» 12+
07.00 Наши в UFC 16+
09.00, 20.45 Матч! Парад 16+
09.25 «Больше, чем бокс. Владимир Гендлин». Специальный репортаж 16+
10.00 «КОМАНДА МАТЧ». Анимационный сериал 0+
10.15 «СПОРТ ТОША». Мультипликационный сериал 0+
10.25 «БОРГ/МАКИНРОЙ» 16+
12.35, 01.45 Голевая феерия Катара! 0+
14.45 «Здесь был Тимур» 12+
15.45 «Шум древнего города». Специальный репортаж 12+
16.15 «География спорта. Кольский полуостров» 12+
16.45 «География спорта. Вершина Теи» 12+
17.15 «География спорта. Тюмень» 12+
17.45 «География спорта. Владикавказ» 12+
18.15 «География спорта. Катар» 12+
18.45 «Год российского спорта». Документальный фильм 12+
19.45 «Лица страны». Лучшее 12+
21.45 Все на Матч! Прямой эфир
22.30 «ГОНКА» 16+
00.50 Автоспорт. Российская Дрифт серия. Гран-при 2022. Итоги сезона 0+
03.35 Матч! Парад 0+
04.00 «Жизнь после спорта. Евгений Трефилов» 12+
04.25 Karate Combat 2022. Трансляция из США 16+

НТВ

05.30 «Таинственная Россия» 16+
06.15 Федор Лавров, Светлана Колпакова. «ГАРАЖНЫЙ ПАПА» (S) 12+
08.00 «Сегодня»
08.20 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
10.00 «Сегодня»
10.20 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
12.25 Константин Юшкевич. «БАЛАБОЛ» (S) 16+
16.00 «Сегодня»
16.20 Детективный сериал. «БАЛАБОЛ» (S) 16+
19.00 «Сегодня»
19.30 Денис Никифоров в детективном сериале «БИМ» (S) 16+
22.23 Премьера. «Новогоднее звездное супершоу» (S) 12+
23.55 Валерий Николаев, Максим Дрозд, Игорь Верник. «ОДИНОКИЙ ВОЛК» 16+
04.25 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Предсказания 2023» 16+
08.20 «СТРАШНАЯ КРАСАВИЦА» 16+
10.20 «ЖЕНА С ТОГО СВЕТА» 16+
14.45 «АЛМАЗНАЯ КОРОНА» 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 93-я – 95-я серии 16+
21.30 «ИЗ СИБИРИ С ЛЮБОВЬЮ» 16+
01.00 «ЕСЛИ ТЫ МЕНЯ ПРОСТИШЬ» 16+
03.45 «ЕСЛИ НАСТУПИТ ЗАВТРА» 16+
05.55 «Предсказания 2023» 16+

ЗВЕЗДА

06.00 «Не факт!» 12+
06.25 «ЛЕТУЧАЯ МЫШЬ» 12+
08.45, 09.15 «КУБАНСКИЕ КАЗАКИ» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
11.00, 13.15, 18.15 «БАБИЙ БУНТ, ИЛИ ВОЙНА В НОВОСЕЛКОВО». 1-я – 12-я серии 16+
23.00 «Легендарные матчи». «Турне московского «Динамо» по Великобритании. 1945 год» 12+
00.50 «МЫ С ВАМИ ГДЕ-ТО ВСТРЕЧАЛИСЬ» 12+
02.25 «СВЕТЛЫЙ ПУТЬ» 12+
04.05 «ГАРДЕМАРИНЫ, ВПЕРЕД!» 1-я и 2-я серии 12+

3 гыйнвар | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

14.35, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» Телесериал 12+
08.00 «Сәйлән-2022» 0+
09.00 «КЛЮЧ К ЕГО СЕРДЦУ» 16+
10.00 «СӨЮ КӨТӘ ЙӨРӘК» 12+
11.50 «Нечкәбил». Финал XVI Республиканского конкурса красоты, материнства и семьи 0+
14.00 «Восточный базар-2022». Гала-концерт I Международного фестиваля эстрады тюркских народов 6+
16.30 «Татарлар» 12+
17.00 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
18.00 «Хуҗа Насретдин мәзәкләре» 12+
18.10 «ЯҢА ЕЛ ТӨНЕНДӘ» 12+
20.00 «АЛМАШ» 12+
20.30 «ХӘСИТӘ» 6+
22.00 «МОЖЕТЕ ЗВАТЬ МЕНЯ ПАПОЙ» 12+
23.45 «СИНЬОР РОБИНЗОН» 16+
01.35 «Секреты татарской кухни». Актеры театра им. Кариева И.Камалиев и Э.Камалиева готовят беккен 12+
02.00 «Каравай». Быт татарского народа 6+
02.25 «Секреты татарской кухни». Сеть быстрого питания «Тюбетейка» 12+
02.45 «Каравай». Современный национальный композитор Л.Тагирова 6+
03.10 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧКӘНДӘ». Телевизион нәфис фильм 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Татарлар» 12+
06.30 «Бөркет канатында хөрлек бар». Язучы Адлер Тимергалин турында телеочерк 6+
07.25 «Тылсымлы бәйрәм мизгелләре» 6+
08.20 «АВЫЛ ЭТЕ АКБАЙ». Балалар өчен спектакль 6+
09.30 «АЛМАШ». Телесериал премьерасы 12+
10.00 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
11.00 «Сәйлән» балалар телевизион фестивале 6+
12.05 «ЯҢА ЕЛДА МИНЕМ ГАИЛӘМ». Телефильм. Икенче серия 12+
13.00 А.Цагарелли. «ХАНУМА». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
15.50 «Чакыра юлларым». Мурат Гайсинның иҗат кичәсе 6+
17.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
18.25 «АЛМАШ». Телесериал премьерасы 12+
19.00 Эшләүче яшьләрнең X «Безнең заман – Наше время» республика телевизион фестивале 6+
21.35 «АЛМАШ» 12+
22.00 «Казаннан – Казанга» 12+
22.40 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». Телефильм 12+
01.45 «Татарлар» 12+
02.10 «Көлке чыбыркысы». «Мунча ташы» эстрада театры спектакле 16+
04.55 «Йөрәктән – йөрәккә». Әсхәт Хисмәт турында телеочерк (субтитрлы) 6+
05.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

1 КАНАЛ

05.15, 06.10 Фильм-сказка «ФИНИСТ-ЯСНЫЙ СОКОЛ» 0+
06.00 Новости
06.40 Фильм-сказка «Золотые рога» 0+
08.00 Телеканал «Доброе утро»
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 «Жизнь своих» (S) 12+
11.10 «ПроУют» (S) 0+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» Новогодний выпуск 0+
13.10 «Повара на колесах». Полная версия 12+
14.15 «ОСОБЕННОСТИ НАЦИОНАЛЬНОЙ ОХОТЫ В ЗИМНИЙ ПЕРИОД» (S) 16+
15.40 «Угадай мелодию». 20 лет спустя (S) 12+
16.25, 18.15 «ОДИН ДОМА 2» 0+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.50 «Фантастика» (S) 12+
21.00 «Время»
21.30 «МАЖОР». Новые серии (S) 16+
22.30 «Сегодня вечером» 16+
00.30 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.15 «ДРУГИЕ» 12+
07.10 «ПЕПЕЛ» 16+
09.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
09.35 «Пятеро на одного»
10.15 «Сто к одному». Телеигра
11.35 «ЛИКВИДАЦИЯ» 16+
14.35 Местное время. Вести-Татарстан
14.50 «ПОСЛЕДНИЙ БОГАТЫРЬ: КОРЕНЬ ЗЛА» 6+
18.00 «Песни от всей души» 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
23.25 «НЕВЕСТА КОМДИВА» 12+
01.25 «МАСТЕР И МАРГАРИТА» 16+
03.20 «ДРУГИЕ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Магия спорта» 12+
06.30, 12.35, 03.35 «Ты в бане!» 12+
07.00, 09.55, 13.05, 15.50, 20.50 Новости
07.05, 13.10, 15.55, 20.15, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.00 «КОМАНДА МАТЧ» 0+
10.15 «СПОРТ ТОША» 0+
10.25 «НЕПОБЕДИМЫЙ МЭННИ ПАКЬЯО» 16+
13.40 Лыжные гонки. «Тур де Ски». Женщины. 10 км. Прямая трансляция из Германии
15.20 «География спорта. Владикавказ» 12+
16.40 Лыжные гонки. «Тур де Ски». Мужчины. 10 км. Прямая трансляция из Германии
17.55 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. ЦСКА – «Динамо» (Москва). Прямая трансляция
20.55 Футбол. Кубок Испании. 1/16 финала. «Эспаньол» – «Сельта». Прямая трансляция
22.55 Футбол. Кубок Испании. 1/16 финала. «Касереньо» – «Реал» (Мадрид). Прямая трансляция
01.45 «БОРГ/МАКИНРОЙ» 16+
03.30 Новости 0+
04.00 «Жизнь после спорта. Анна Чичерова» 12+
04.25 Смешанные единоборства. АСА. Виталий Слипенко против Абубакара Вагаева. Трансляция из Москвы 16+

НТВ

04.55 «ГОРЮНОВ» 16+
08.00 «Сегодня»
08.20 «ЛЕСНИК» (S) 16+
10.00 «Сегодня»
10.20 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
12.25 «БАЛАБОЛ» (S) 16+
16.00 «Сегодня»
16.20 «БАЛАБОЛ» (S) 16+
19.00 «Сегодня»
19.30 «БИМ» (S) 16+
22.23 «Перелистывая страницы от сердца к сердцу». Концерт к 90-летию Бедроса Киркорова (S) 12+
00.15 «ОДИНОКИЙ ВОЛК» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Предсказания 2023» 16+
07.45 «МУЖЧИНА В МОЕЙ ГОЛОВЕ» 16+
10.15 «МОЙ МИЛЫЙ НАЙДЁНЫШ» 16+
14.50 «В ТИХОМ ОМУТЕ...» 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 96-я – 98-я серии 16+
21.35 «СТРАШНАЯ КРАСАВИЦА» 16+
23.40 «БУМ» 16+
01.30 «БУДЬ ЧТО БУДЕТ» 16+
04.25 «ЕСЛИ НАСТУПИТ ЗАВТРА» 16+
05.50 «Домашняя кухня» 16+
06.10 «ИЗ СИБИРИ С ЛЮБОВЬЮ» 16+

ЗВЕЗДА

06.35 «ГАРДЕМАРИНЫ, ВПЕРЕД!». 3-я и 4-я серии 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.15 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал 12+
10.00 «Загадки века» 12+
10.45 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Гитлер. История болезни» 12+
11.30, 12.15, 15.20, 16.55 «Загадки века» 12+
13.15 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Гарвардский проект. Психологическая война против СССР» 12+
14.00 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Капкан для Скифа» 12+
14.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Жизнь по легенде. Судьба разведчика-нелегала» 12+
16.10 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Секрет советской искусственной крови и загадка гибели её изобретателя» 12+
17.35, 18.15 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Виктор Луи. Личный агент Андропова» 12+
18.35 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Фальшивые червонцы» 12+
19.10 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Реальная история Анки-пулемётчицы» 12+
20.00 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Кремлёвские пенсионеры» 12+
20.45 «Загадки века». Док. сериал. «Нюрнберг. Свидетель Паулюс» 12+
21.30 «СЕМЬ НЯНЕК» 12+
23.00 «Легендарные матчи». «Чемпионат мира 2006. Волейбол. Женщины. Финал. Россия – Бразилия» 12+
02.10 «ЗЕЛЕНЫЙ ФУРГОН» 12+
04.25 «БЛИЗНЕЦЫ» 6+

ЯЛНЫҢ ДА ТӘРТИБЕ БАР

КАНИКУЛ ФАЙДАЛЫ УЗСЫН ӨЧЕН 7 КИҢӘШ

Көтеп алган озын-озак Яңа ел ялларына да санаулы көннәр генә калып бара. Алда рәхәтләнеп ял итәр, киләсе елга җитәрлек көч һәм дәрт җыярлык көннәр көтә. Әмма белгечләр ял иткәндә дә чама хисен югалтмаска киңәш итә. Яңа ел ялларын файдалы һәм нәтиҗәле итеп үткәрү өчен берничә кагыйдәне истә тотарга куша алар.

1 Өйдә торганда гел ашыйсы килү – гадәти хәл. Бәйрәм көннәрендә бигрәк тә. Шулай да бу очракта да чама хисен югалтырга ярамый. Бәйрәм ялларында күбрәк хәрәкәтләнергә, ешрак, әмма аз-азлап ашарга тырышыгыз.

2 Ял иткәндә интернет, социаль челтәрләрдән читләшеп тору да хәерле. Артык күп мәгълүмат, бердән, вакытны «яндыра», икенчедән, кешегә игътибарын тупларга комачаулый, күңел тынычлыгын ала. Шуңа күрә ялларда телефонны кулга сирәк алып, вакытны күбрәк якыннарыгыз белән бергәләп уздырырга тырышыгыз.

3 Яңа елга кадәр башкарып өлгермәгән «койрык»ларыгыз булса, аларны эшкә чыккан чорга калдырыгыз. Ял ул ял итәр өчен. Сезнең ни дәрәҗәдә тыныч һәм рәхәт ял итүегез эшегезгә дә йогынты ясый бит.

4 Күңелегезгә якын кешеләр белән аралашыгыз. Яңа ел бәйрәме – дуслар, туганнар, җанга якын кадерле кешеләрең белән күрешү өчен менә дигән чор. Шуңа күрә бу мөмкинлектән файдаланып калырга ашыгыгыз. Ялгыз калып, уй-фикерләрегезне тәртипкә китерергә дә вакыт табыгыз.

5 Озын ялларда яңа елга планлаштырган күп кенә эш-гамәлләрне башкарып, сынап карарга да вакыт күп була. Һәр көн иртүк гимнастика ясарга хыялланган булсагыз, хәзер моның өчен менә дигән вакыт. Чит тел өйрәнү, музыка уен коралында уйнап карау кебек барлык хыялларны чынга ашыру өчен дә кулай чор бу. Бер башлагач, бу гадәтләрегезне эшкә чыккач та дәвам итү җайлы булачак.

6 Озын ялларда көнлек режим да бозыла. Теләсә кайсы вакытта ятып йоклау, соң яту һәм соң уяну… Гыйнвар башында үзеңне шул рәвешле кадерләүнең зыяны юк, билгеле. Әмма эшкә чыгар көннәр якынлашкан саен акрынлап йокы режимын җайга сала башларга кирәклеген дә онытмагыз. Моның өчен гел бер вакытта йокларга ятып, бер вакытта йокыдан тора башларга кирәк. Игътибар: бу кагыйдә авыл кешесенә кагылмый!

Илдар Мөхәммәтҗанов

7 Озын яллар вакытында организм турында да истән чыгарырга ярамый. Ашкайнату системасы тиз арада рәткә килсен өчен, рационга ачы сөт ризыклары кертергә кирәк, ди белгечләр. Ник дигәндә, аларның составында ашказаны-эчәк тракты эшчәнлеген яхшыртучы биологик актив матдәләр күп. Тозлы кыяр белән тозлы помидорга да өстенлек бирергә киңәш итә алар. Алар микрофлораны яхшырта, эчәклектәге газларны киметә.

КҮЗ ДӘ ТУЙСЫН

Ел буе көтеп алган Яңа ел җитә. Берәүләр бәйрәмне кайда уздырачагын уйлап баш ватса, уңган хуҗабикәләр табында ниләр булачагын планлаштыра. Бәйрәм табыныннан туп-туры хастаханәгә юл алмас өчен ни эшләргә? Яңа ел кичен сау-сәламәт уздыруның сере нидә?

Табиб-терапевт, гастроэнтеролог Индира ГЫЙМАЛТДИНОВА шул сорауларыбызга ачыклык кертте.

vk.com

:: Индира Мөнировна, Яңа ел төненнән соң сезгә нинди зарлар белән күбрәк мөрәҗәгать итәләр?

– Мул табыннар янында сыйлану, ачы-төче, кыздырылган ризыкларны чамадан тыш ашау үзенекен итә. Бәйрәм чорында иң беренче чиратта ашказаны, эчәк авырулары баш калкыта. Шуңа күрә безгә күбрәк эч авырту, сару кайнау, кикергәндә ачы су килү, эч кату, күңел болганудан зарланучылар мөрәҗәгать итә. Гастрит, үт куыгы белән ашказаны асты бизе ялкынсынудан тилмергән кешеләр Яңа ел ялларында аеруча сак булсын иде.

:: Бәйрәм табынында безне нинди куркыныч сагалый?

– Бүген күпләр Яңа ел табынының классик вариантыннан баш тарта. Без бит бәйрәм өстәлендә элек-электән «тун»лы сельдь, оливье салатлары, кыздырылган каз булганга күнеккән. Бүген исә арабызда бәйрәм табынына дигән ризыкларны парда яки томалап пешерүчеләр шактый. Болай эшләгәндә, ризык бик җиңел үзләштерелә. Гомумән, бүген дөрес туклануга күчүчеләр саны көннән-көн арта бара. Шуңа күрә хәзерге бәйрәм табыннарында әллә ни зур куркыныч сагалый дип әйтә алмыйм.

БӘЙРӘМ КӨННЕ АРТЫК АШАМАС ӨЧЕН НИ ЭШЛӘРГӘ?

★Кайберәүләр, бәйрәм алдыннан аз булса да бушанып алам дип, ач тора. Бу – бик зур хата. Озак вакыт ач торып ашаганда, ашказанына икеләтә зур зыян килә. Шуңа күрә бәйрәм алдыннан тамагыгыз тук булсын.

★Кунакта хуҗалар кыстаган саен, «яхшы түгел» дип, тәлинкәгә салган һәр ризыкны ашап бармагыз. Хуҗабикә, кунаклар ач кайтып китмәсен, дип тырыша. Аны да аңлап була. Әмма сез дә үз чиратыгызда итагатьле итеп кенә «юк, рәхмәт» дип әйтергә курыкмагыз.

★Мөмкинлек булса, кечкенә тәлинкәдән ашарга тырышыгыз. Анда салынган ризык карап торышка бик күп кебек тоелса да, чынлыкта сез бик аз күләмдә ашаячаксыз.

★Ризык янында артык озак утырып, басып, ятып торырга да киңәш итмәс идем. Үзегезгә берәр шөгыль табасызмы, биисезме, якыннарыгыз белән аралашып, йә булмаса телевизор карап ял итеп аласызмы – мөһим түгел. Иң мөһиме – өстәл янынннан вакытында китә белергә кирәк.

★Десерттан баш тартыгыз. Төнгә каршы баллы ризык ашау – организм өчен зур сынау.

★Игътибар иткәнегез бардыр: бәйрәм табыны янында, гадәттә, берәүләр сөйләгәндә, икенчеләре тыныч кына ашавын белә. Әңгәмәгә сез дә кушылыгыз. Җанлы аралашу ризык белән генә мавыгырга ирек бирмәс.

★Бәйрәм көнне дә гадәттәгечә 1,5–2 литр су эчәргә онытмагыз.

★Ризыкны аз-азлап, билгеле бер вакыт аралыгында ашау хәерле.

★Үз-үзегезгә: «Бәйрәмнән соң диетага утырам», – дип вәгъдә итмәгез. Шул хакта уйлап, бәйрәм кичендә артыгын ашап ташлавыгыз бар.

★Бәйрәм ялларында көнгә 4–5 тапкыр аз-азлап ашасаң, хәерле. Бер ашау белән икенче ашау арасында өч сәгать аерма булсын.

:: Яңа ел өстәленең тагын бер алыштыргысыз «сые» булган шампан шәрабе турында ни әйтерсез?

– Өстәлдә төп сыеклык су булырга тиеш. Ул матдәләр алмашын яхшырта, ашказанындагы юк-бар калдыкларны да юып төшерә. Дөрес, Яңа ел киче алкогольле эчемлекләрсез генә узмый. Монда да чама хисен югалтмаска кирәк. Табиб буларак, 1–2 бокал шампан шәрабе яки ак коры шәраб эчеп куюның зыяны юк дияр идем. Әмма бер бокал шәраб эчкәч, бер стакан су эчеп куярга да онытмагыз. Бу кагыйдәне үтәсәгез, икенче көнне башыгыз да авыртмас, авырлыгым арта дип тә куркасы юк.

УЗГЫНЧЫ БУЛСЫН, ДИСӘҢ...

Мең дә бер киңәш

Көз, кыш айлары организм өчен еш кына җитди сынауга әверелә. Көннәр аз гына суыттымы – шундук төчкертә, йөткертә башлый. Тамак та калышмый. Болар бар да вакытлы борчу булсын өчен ни эшләргә?



Ютәл башланса

Бер баш суганны вак кына тураганнан соң, өстенә кайнар су коеп, биш минут төнәтәсең. Шуны ике-өч минут эчендә аз-аз йотымнар белән эчеп куясың. Ютәл вакытында бал, глицерин һәм лимон сутын бертигез алып, яхшылап болгатырга һәм көненә өч тапкыр берәр чәй кашыгы кабып куярга киңәш итәлә. Эвкалипт яфрагы яисә бөтнек белән даими ингаляция ясау каты ютәлне дә басарга мөмкин. Әлеге үләннәрнең эфир маен да кулланырга була.

Тамак авыртса

Тамак төбе борчый башлауга да бармак аша карарга ярамый, ди табиблар. Беренче көнне үк тамакны көненә берничә тапкыр үлән төнәтмәсе белән чайкатырга кирәк. Ромашка, шалфей яки тырнак гөл төнәтмәсенең файдасы озак көттермәс. Моның өчен стаканга бер аш кашыгы үлән салып, өстенә кайнап торган су коясың да 15–20 минут каплап тотасың. Аннары тамакны чайкатасың. Муенга компресс куюның да файдасы булмый калмас. Моның өчен марля кисәген җылытылган көнбагыш маена манып, авырткан урынга ябасың. Өстенә балавызлы кәгазь яисә пленка каплап, җылы шарф белән урап куясың.

Тест

Сездән нинди табиб чыгар иде?

Сезнең янга килеп, «Фәлән урамны кайдан табарга?» – дип ярдәм сорасалар, сез:

а) бер сүз дәшмичә генә, шул урам ягына төртеп күрсәтәм;
б) әлеге урамда конкрет нинди бинаны эзләве белән кызыксынам;
в) телефонымны ачып, шундагы карта буенча юл аңлата башлыйм;
г) белгән очракта да, аңлатып маташмаячакмын. Кирәк кеше үзе тапсын.

Китап укыганда сез:

а) ара-тирә китапның ахырына карап алам, әсәрне бер уңайга гына укып барырга түземлегем җитми;
б) сюжеты белән генә кызыксынам;
в) төге яки бу геройның ни өчен шулай эшләгәненә анализ ясап, аларга бәя бирәм;
г) китап укудан да күңелсез шөгыль юктыр ул.

Кафега кергәч, нинди ризыкка заказ бирәсез?

а) тиз әзерләнә торган;
б) моңарчы бер тапкыр да авыз итеп карамаган ризыкка;
в) үзем яраткан ризыкка гына;
г) менюдагы иң экзотик ризыкны күрүләрен сорыйм.

Салкын тисә, сез:

а) температураны төшереп, борынга дару салам да эшкә китәм;
б) чирне башкаларга йоктырмас өчен, бер атна өйдә утырам, дәваланам;
в) миңа чынлап та салкын тигәнме икән дип, интернетта «казынам»;
г) бернәрсә дә эшләмим. Үзе үтеп китә ул.

Балачактагы иң яраткан уенчыгыгыз:

а) конструкторлар;
б) теләсә кайсы яңа уенчык яраткан уенчыгыма әверелә иде;
в) пазллар;
г) тимераяк һәм роликлар.

НӘТИҖӘ:

«а» җавабы күбрәк булса: сездән бик яхшы хирург яки теш табибы чыгар иде. Авыруны дару һәм уколлар ярдәмендә озаклап дәвалау сезнең өчен түгел. Сез тиз арада нәтиҗәгә ирешергә күнеккән.

«б» җавабы күбрәк: сез – менә дигән терапевт! Иң мөһиме – дөрес диагноз кую. Вак-төягендә тар белгечләр баш ватсын! Өстәвенә авыру белән озак-озаклап сөйләшеп, аның бик сәер кебек тоелган аһ-зарларын тыңлап утырырга да түземлегегез җитәрлек.

«в» җавабы күбрәк: сездән бик яхшы күз табибы, невролог кебек тар белгеч чыгар иде. Бер мәсьәләне алып, аны төбенә төшкәнче җентекләп өйрәнү – сезнең холыкка туры килә торган сыйфат.

«г» җавабы күбрәк: кешеләрне әллә ни яратмыйсыз, күбрәк ялгызлыкка өстенлек бирәсез. Аның каравы тәвәккәллекне яратасыз. Шуңа күрә авырулардан ерак торуыгыз хәерлерәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Гөлнара
ЗИННӘТУЛЛИНА

ТЕЛӘК ТЕЛӘР ЧАК

Яңа елга санаулы сәгатьләр калып бара. Без һәр елны могҗиза көтеп каршылыйбыз. Шул көткәннәр чынга ашсын өчен, теләкләрне дөрес итеп тели белергә дә кирәк.

Психолог, коуч Лилия ДӘҮЛӘТШИНА безгә дөрес итеп теләк теләү серләрен ачты.

Рәхмәт әйтү. Теләкләр теләр алдыннан берничә минут вакытны үзегезгә багышларга кирәк. Узып баручы елда нинди уңышларга ирештегез? Шуларны уегызда яки язып барлап алыгыз. Алдагы елны планлаштырган һәм тормышка ашкан теләкләрегез өчен Аллаһы Тәгаләгә чын күңелдән рәхмәт әйтегез. Үз эшегезгә анализ ясау бик мөһим. Бу – бердән, елга йомгак, икенчедән, сез үз мөһимлегезне тоясыз. Рәхмәтле булу югары вибрацияләргә ия. Галәм моны бездән «укый». Шатланган, максаты тормышка ашкан кешеләрнең бәхете, рәхмәте тагын да зуррак уңышларга юл ача.

Теләк белән максат яңашә. Теләкләрне язганда, инде ул сезнең белән булган, тормышка ашкан, теләгән нәтиҗәләргә ирешкән кебек итеп язарга һәм юклык кушымчалары кулланмаска кирәк. Мәсәлән, «Минем балаларым авырмасын», – дип түгел, ә «Минем балаларым сәламәт», – дип язарга.

Кайбер үрнәкләр:

✓ «Минем ирем белән мөнәсәбәтләрем яхшы».
✓ «Эшемдә зур уңышларга ирештем».
✓ «Мин аена 80 мең сумнан артык хезмәт хакы алам» (сумманы үзегез өчен күпме кирәк шулай язасыз).
✓ «Минем сәламәтлегем яхшы».
✓ «Мин тынычлыкта рәхәт гомер итәм».
✓ «Мин – яңа кызыл машина иясе».
✓ «Мин елына ике тапкыр яхшы курортларда ял итәм».
✓ «Минем фигурам идеаль».

Бу психикага уңай тәэсир итә һәм безнең үзбәябез һәм мөһимлегебезне арттыра. Безнең үзебезгә ышанычыбыз арта, кыюрак һәм көчлерәк булабыз. Уңышларны шулай үзебезгә «бәйләп», эчке таянычыбызны ныгытабыз. Без соңгы нәтиҗәгә генә карамыйбыз, ә аңа ирешкәндә нинди сыйфатларыбыз булышасын күзаллап эш итәбез. Әлеге теләккә ирешү юлында безниләр кичердек соң? Шул рәвешле без үзебез үткән юлны һәм кыюлыгыбызны бәяләргә өйрәнәбез.

Уңыш сере – үзебездә. Теләк булу – уңышның 50 проценты дигән сүз. Без теләкләребезне максатка әверелдергәндә, аның үзебез ирешергә теләгән вакыт, адымнарын һәм ни өчен кирәк булуын билгелибез. Теләкнең тормышка ашуы миңа һәм башкаларга ничек тәэсир итәчәк? Максат, теләк һәм әлеге эшкә алыну аның 100% тормышка ашуына сәбәпче була.

Хыял, теләк, максат – бонуслар гына. Аларны тормышка ашыру юлында кыю, көчле үзебезне табу – иң мөһиме. Шуннан соң безнең өчен чынга ашмастай теләкләр булмаячак!

Тәмле булсын!

Табын әзерләү – ләззәт ул

Бәйрәм алды ел ахырында төгәллисе эшләре, мәшәкате белән алҗыта. Табын кору буенча Seviyorum хатын-кызлар клубына нигез салучы Ильмира Каракуш укучыларыбызга киңәшләрен бирде. «Вакытны да, акчаны да экономияләп табын коруның бер кыенлыгы да юк. Төп киңәшем: майонезлы салатлар белән табын тутырмагыз. Җиңелчә, ансат әзерләнә торган ризыклар белән дә Яңа елны менә дигән итеп каршылап була», – ди ул.

Яшелчә. Яшелчәләрне табын бизәге итим дисәгез, зуррак черри помидорларыннан лалә чәчәкләре ясарга була. Моның өчен помидорларны лалә сыман итеп бөтенләй үк кисеп бетерми генә кисәргә һәм, моцарелла сырының шарсыманын кисеп, лаләләрнең уртасына салып чыгарга кирәк. Яныңа төшсә кара зәйтүн, буйга киселгән кыяр һәм борыч тезәргә була.

Җиләк-җимеш. 10 кешелек табын корырга 2 алма, 1 грейпфрут, 2 киви, 1 әфлисун, бер зур булмаган тәлгәш виноград җитә. Грейпфрут, әфлисун, кивины табынга чистартып куегыз. Болай иткәндә ашарга да уңайлы, өстәл дә чүпләнми.

Брускетта. Әлеге ризык шулай ук хәзер модада. Аңа махсус озынча икмәк (чиабатта әйбәт була) кирәк. Аны буйга кисәргә. Сарымсак (кипкән яки чи) белән ышкырга һәм ак май сыларга. Брускеттаны теләсә нәрсәдән әзерләргә була. Тавык ите, гөмбә, помидор һәм сыр сибеп, 10 минутка мичкә озатырга. Яшелчәдән генә булсын дисәгез, бер болгар борычын мичтә бераз пешереп, аны әрчергә, турарга һәм өстенә сыр сибеп, 10 минутка мичкә куеп алырга. Кетердәп торган ризыкны яшьләр аеруча ярата.

Лимонад. Суыткычта дүрт көнгә кадәр саклана. 5 литрга 3 әфлисун, 4 лимон кирәк. Аларны кабыклары белән угычтан уарга, иттарткычтан чыгарырга яки турарга була. Салкын су һәм түбәнчә шикәр комы салып, 2–3 сәгать тотарга һәм сөзеп, бизәп табынга бирергә.



Жульен. Ул тиз әзерләнә, тәмле һәм кышкы ризык санала. 500 г тавык ите, 600 г гөмбәне турарга. Башта тавыкны кыздырыгыз, аңа тулыр-тулмас чәй кашыгы бөтнек өстәгез, ул тәмне ачып җибәрә. Шулай ук түбәнчә тоз, кипкән яки чи сарымсак, теләсәгез, суган салырга була. 10 минуттан соң, аңа гөмбә салып кыздыруны дәвам итәсе. Ахырда каймак салып, тагын 10 минут, бераз кимегәнче пешерәбез. Эчлек әзер. Аны уалып тора торган камырлы (песочный) кәрзиннәргә өеп салыгыз һәм өстенә бер кашык уылган сыр сибегез. 10 минутка мичкә тыгып алыгыз.

Оливье салатын да кәрзиннәргә салып куйсагыз була. Бу, бердән, уңайлы, тәлинкәләр алыштырып торасы булмый, икенчедән, тәмле дә.

Креатив салат. Айсбергны кул белән уртача зурлыкта ваклыйбыз, эремчек сыры (творожный сыр) салып болгатабыз. Ә аннан соң фантазиягезне эшкә җиксәгез дә була. Киви, гранат, пешкән тавык ите, болгар борычы, черри помидоры өстәргә була. Өстенә адыгея сыры һәм вакланган әстерхан чикләвеге сибеп, табынга бирәсе. Санап үткән ингредиентларның кайсын өстисе килә, шуны өстәгез. Тоз салмасаң да була. Файдалы, тәмле, тиз генә бозылмый.

Ләвәштәге булгур. Яхшылап юылган булгурны үсемлек мае, өстенә бераз чыгарлык итеп су салып, 10–15 минут пешерергә. 150 г атланмай, түбәнчә тоз салырга. Туралган итне суган, башка тәмләткечләр белән пешереп алырга. Озынча ике зур ләвәшне, казан төбен майлап, ике яктан бәлеш камыры төсле асылынып торырлык итеп салырга. Эченә ит, өстенә булгурны салып, калган камыры белән өстен каплап майларга һәм мичкә 10 минутка тыгып алырга кирәк. Ләвәшкә май, ит тәме сеңә, кертердәп тора торган була. Аны зур савытка әйләндереп каплыйсың һәм кисәсең. Ул чәчәк сыман ачыла, бик тәмле була.

ИШКӘ ИШ КИРӘК

Узып баручы елның соңгы көннәрен ваклыйбыз. Кылган гамәлләргә нәтиҗә ясап, киләсе елга якты өмет-хыяллар белән аяк басар чор. Күп кенә сорауларга да җавап табып өлгерәсе килә. Бүгенге сәхифәбездә дә укучыларыбызны кызыксындырган сорауларга җавап эзләрбез.

Сорауларга «Иман нуры» мәчетенең икенче имам-хатыйбы Әхмәт хәзрәт ФӘЙЗУЛЛИН җавап бирде.

? Мәһәр бирелмичә укылган никах дөрес буламы?

– Никах вакытында мәһәр бирелмәсә, никах дөрес була. Ләкин ир кешегә мәһәрне түләү барыбер тиешле булып кала. Шундый никахның дөрес булуы турында Бәкара сүрәсенең 236 нчы аятендә дә әйтелә. Анда: «Әгәр сез хатыннарга [якынлык кылу белән] кагылганчы һәм мәһәр билгеләгәнче, аларны талак кылсагыз, сезгә [мәһәр мәсьәләсендә] гөнаһ юк», – дигән юллар бар. Бу аятьтә мәһәрне билгеләгәнче аерылышу турында әйтелә. Моннан чыгып, мәһәрне биргәнче үк никахны уку дөрес була.

? Мәрхүмнең кырыгын ул туры килгән көннән иртәрәк яки соңрак уздырырга ярыймы? Бабабыз үлеп китте. Кырыгы эш көненә туры килә. Шуңа ашны ял көне үткәрсәк дигән идек.

– Өчесен, җидесен, кырыгын уздыру безнең җирлектә гореф-гадәт булып тора. Ул мәҗлесләрнең максаты – мәрхүм булган кеше өчен дога кылу, Коръән аятьләрен укып, аның рухына багышлау. Шуңа күрә аларны иртәрәк яки соңрак үткәрүнең зыяны юк.

? Мөселманнарга кешбэк (түләгән акчаның бер өлешен кире кайтару) куллану рөхсәт ителәме?

– Кешбэк ул, әлбәттә, безнең өчен яңа, заманча әйбер булып тора. Шуңа күрә аның хөкеме турында галимнәр арасында төрле фикерләр бар. Аларның бер ише аны кулланырга ярый ди, кемдер хәрам ди. Ләкин пәйгамбәребезнең сүзләрен истә тотарга кирәк. «Дөреслектә, хәләл нәрсәләр ачык, хәрам нәрсәләр ачык, һәм алар арасында шикле әйберләр бар, алар хакында күп кешенең аңлавы юк. Шикле әйберләрдән сакланучы, үз динен һәм намусын саклап калу өчен, аннан ерак булыр, ә шикле әйберләр белән шөгыльләнүче хәрам эшләргә дә кереп китәр...» – ди ул. Димәк, ялгыш хәрамга кереп китмәс өчен, андый әйберләрне кулланмый торсак хәерле булыр.

? Аштан кайткач, җыелган сәдаканы үз балаңа бирергә ярыймы? Гомумән, ата-ананың үз баласына сәдака бирүе дөресме?

– Сәдака өч төрле була. Фарыз булган сәдаканы зәкәт дип атыйлар. Вәҗиб булган сәдака ул – ураза бәйрәмендә бирелә торган фитыр сәдакасы. Өченчесе – нәфел сәдакасы. Беренче ике төре – мөселман булган мохтаҗларга гына бирелә торган сәдакалар. Аларны нәселнең туры ботагында булган туганнарга, ягъни әти-әни, әби-бабай, балалар, оныкларга бирергә ярамый. Нәфел сәдакасын исә бөтен кешегә, хәтта иреңә, хатыныңа, балаларыңа да биреп була.

? Йөргән егетем намаз укымый. Вакыты җитмәгән, ди. Мин үзем – намазда. Безгә очрашырга ярыймы?

– Кызга өйләнергә җыенган егет аның диненә һәм диндарлыгына туры килергә тиеш. Ник дигәндә, Мөхәммәд пәйгамбәребез (с.г.в.): «Хатын-кызларны кияүгә туры килгәннәргә бирегез...» – дигән. Әгәр хатын-кыз үзенә туры килмәгән егеткә кияүгә чыкса һәм кызның вәлие (әтисе, абыйсы) ризалыгы булмаса, никах дөрес булмас. Шуңа күрә, киләчәктә гаиләдә ныклы мөнәсәбәт булуын теләсәгез, ирнең рухи яктан терәк булуы мөһим. Әгәр дә сезнең әти-әниегез бу егет белән гаилә коруыгызга каршы булмаса, кияүгә чыгарга мөмкин. Бәлки Аллаһы Тәгалә сезнең аша аның йөрәген ачар һәм ул шулай ук намаз укый башлар.

Никах алдыннан очрашуларга килгәндә, кайбер чикләүләр бар. Егет һәм кыз ялгыз кала алмыйлар, чөнки бер хәдистә: «Әгәр кемдер (ирләрдән) чит хатын белән ялгыз чыкса, алар арасында өченчесе, әлбәттә, шайтан булыр», – диелә. Бу сүзләрнең мәгънәсе шунда: ир-ат һәм хатын-кыз бергә калгач, шайтан аларны гөнаһка этәрәчәк. Аралашу өченче як кешеләре – дуслар яки туганнар катнашында булырга тиеш. Сезгә мөһим сораулар турында турыдан-туры сөйләшү өчен калырга мөмкин, ләкин шулай ук якын туганнарыгыз күзәтүендә. Никахка кадәр сез – бер-берегезгә чит кешеләр, шуңа күрә сезнең арада элемтә булмавы мөһим. Хәтта кул тоту да рөхсәт ителмәячәк. Никахны кичектермәскә тырышыгыз. Әгәр дә сез кешенең сезгә туры килүен аңласагыз, гаилә корыгыз, сузмагыз.

? Дога язылган тәлинкә төшеп ватылды. Аның кыйпылчыкларын нишләтергә? Ташларга ярыймы?

– Дога, аятьләр язмалары изге сүзләр булып тора, шуңа күрә аларга ихтирам күрсәтергә кирәк. Шуңа күрә аларны чиста, кешеләр йөрми торган урынга күмеп кую хәерле булыр.

? Кешегә Коръән китабы, тәсбих, намазлык бүләк итәргә ярыймы?

– Әлбәттә, бу бик күркәм бүләк булыр. Ләкин Коръәнне бүләк иткәндә, аны тәһарәт белән генә тотарга рөхсәт ителүен истән чыгармаска кирәк.

? Бер мәҗлестә булырга туры килде. Анда намазда булган кешеләр өчен аерым өстәл әзерләнгән иде. Мәҗесләрдә намаздагы кешеләрне аерым өстәлдә утырту дөресме? Мөселман мәҗлесләрендә биергә, җырларга ярыймы?

– Мәҗлесләрне оештырганда, утыру мәсьәләсендә үзенең тәртипләре бар, әлбәттә. Мәсәлән, бер-берсенә чит булып килгән ир белән хатын-кыз янәшә утырырга тиеш түгел. Ирләр аерым, хатын-кызлар аерым өстәл янында утырса хәерле. Намаз укучымы, юкмы – монда андый шарт юк. Ягъни намаз укымаучылар намаз укучылар белән утыруда бернинди зыян юк. Минем аңлавымча, андый очраклар хәмер булган мәҗлесләрдә килеп чыга. Дин тотучыларга аерым хәмерсез өстәл куялар. Ләкин пәйгамбәребездән шундый мәгънәдә сүзләр китерелә: «Хәмер мәҗлесендә утыручы аны эчүчегә тиң», – ди ул. Шуңа күрә, әгәр дә мәҗлестә хәмер булачагы билгеле икән, андый мәҗлескә бару тыелган.

Гыйнвар аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ясту намазы
1	Якш	05:53	08:13	13:33	15:20	17:18
2	Дүш	05:53	08:12	13:34	15:22	17:19
3	Сиш	05:53	08:12	13:35	15:23	17:20
4	Чәрш	05:52	08:12	13:37	15:24	17:21
5	Пәнҗ	05:52	08:11	13:38	15:26	17:22
6	Җом	05:52	08:11	13:39	15:27	17:23
7	Шим	05:52	08:10	13:41	15:28	17:25
8	Якш	05:51	08:09	13:42	15:30	17:26
9	Дүш	05:51	08:09	13:43	15:31	17:27
10	Сиш	05:51	08:08	13:45	15:33	17:28
11	Чәрш	05:50	08:07	13:46	15:35	17:30
12	Пәнҗ	05:50	08:06	13:48	15:36	17:31
13	Җом	05:49	08:05	13:50	15:38	17:32
14	Шим	05:48	08:04	13:51	15:40	17:34
15	Якш	05:48	08:03	13:53	15:42	17:35
16	Дүш	05:47	08:02	13:55	15:44	17:37
17	Сиш	05:46	08:01	13:56	15:45	17:38
18	Чәрш	05:45	08:00	13:58	15:47	17:40
19	Пәнҗ	05:45	07:58	14:00	15:49	17:41
20	Җом	05:44	07:57	14:02	15:51	17:43
21	Шим	05:43	07:56	14:03	15:53	17:45
22	Якш	05:42	07:54	14:05	15:55	17:46
23	Дүш	05:41	07:53	14:07	15:57	17:48
24	Сиш	05:39	07:51	14:09	15:59	17:49
25	Чәрш	05:38	07:50	14:11	16:01	17:51
26	Пәнҗ	05:37	07:48	14:13	16:03	17:53
27	Җом	05:36	07:46	14:15	16:06	17:55
28	Шим	05:35	07:45	14:17	16:08	17:56
29	Якш	05:33	07:43	14:19	16:10	17:58
30	Дүш	05:32	07:41	14:21	16:12	18:00
31	Сиш	05:30	07:39	14:23	16:14	18:02

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Йөгез, бер дога!

КҮЗ ТИЮДӘН САКЛЫЙ

Пәйгамбәребез оныклары Хәсән белән Хөсәенгә бу доганы укыган: «Әгузү би-кәлимәти-лләхи-ттәммә; мин күлли шәйтанин уә хаммә; уә мин күлли гайнин ләммә». *Мәгънәсе:* «Мин сезне ике дөньяда булучы һәртөрле явызлыктан, һәрбер агулы еланнан һәм һәрбер яман күздән саклауны Аллаһка тапшырам».

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Лилия
ГЫЙМАЗОВА

Бәйрәм хатирәсе

«Ни хәл?» сәхифәсенең бәйрәм чыгарылышы кунакларыннан Яңа ел хатирәләре турында сораштык. Кайсы елны каршылау аеруча исләрендә калган икән?

Разил КАМАЛОВ, баянчы:
– Иң истә калган Яңа ел, диюгә, балачак искә төшә. Бигрәк тә мәш килеп мәктәптәге Чыршы бәйрәменә әзерләнгән чаклар. Бал-маскарадта катнашыр өчен, миңа әни, апа, абый костюм тегәргә булыша иде. Башлангыч сыйныфларда укыганда, 1997–2000 еллар була инде ул, мин куян да, тылсымчы да, казак та булып карадым. Ул чакта бездә авылыбызга бер фотоаппарат бар иде. Әнигә рәхмәт: бәхетле, истәлекле мизгелләрне «эләктереп», фотосурәтләр ясап калган. Алар әле дә саклана.

Эльвира ХАММАТОВА, җырчы:
– Әйтәләр бит әле: әгәр чынбарлыкны үзгәртә алмасаң, димәк, моңа мөнәсәбәтеңне үзгәртергә кирәк, диләр. Менә мин дә шул фикердә. Кулда булганның барлык уңай якларын барлап чыгам да, шул әйбергә чын-чынлап гашыйк булып, рәхәтләнеп яшим. Минемчә, чит ил брендлары китүенә артык борчылырга кирәкми. Суыткыч, индукцияле плитә, мич ише аш бүлмәсе техникасы сатып алдык. Аларны Мәскәүдән кайтардылар. Алла боерса, бурычларны исән-сау түләп бетерергә язсын. Беренче катны җиһазлап бетердек инде, – ди Зөлфия Вәлиева.

Искесе дә ярый

Аңлашыла ки, яңа суыткыч яки үтүк сатып алырга теләүчеләр ничек тә акчаны янга калдырырга тырыша. Берәүләр, ташлама эзләп, интернет-кибетләргә кереп «чумса», икенчеләр исә рассрочка, ягъни банк ярдәменнән башка гына товар өчен кичектереп түләү мөмкинлегеннән файдаланып калырга ашыга. Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың, дигәндәй, ел башыннан бирле халыкка кичектереп түләү мөмкинлеген тәкъдим итүче кибетләр саны тугыз тапкыр арткан. Бүген көнкүреш техникасы сатучылар гына түгел, ә бала киемнәре, косметика кибетләрендә дә акчаны өлешләп түләү мөмкинлеге белән кызыктыралар.

«Сбербанк»ның Казандагы идарәсе белгече Алсу Нуриева сүзләренә караганда, бу – ике як өчен дә отышлы.

– Товар өчен кичектереп түләгән очракта, бурычка процент исәпләнми. Димәк, сатып алучылар берни югалтмый. Бүген беркемнең дә артык акчасы юк. Шуңа күрә кибетләрнең кичектереп түләү белән кызыктыруларына артык гаҗәпләнергә кирәкми. Алар сату дәрәҗәсен сакларга тырыша. Өстәвенә кичектереп түләү – уртача чек, ягъни сатып алучылар кибеттә калдырган акчаның гомуми суммасын да арттыра. Банк картасы белән исәп-хисап ясаганда күпме акча тудзырганны контрольдә тоту кыен бит. Бу да шул ук. Кичектереп түләү мөмкинлеге булгач, кыйммәтрәк кесә телефонына күз төшә башлый.

Ул арада кулланылышта булган көнкүреш техникасына сорау артты, ди башкаладагы ломбард хезмәткәре Тимур Тихонов.

– Элек безгә нигездә фен, чәйнек, блендер ише вак-төяк техника гына тапшыралар иде. Аның сораучысы да әллә ни булмады. Хәзер арзанрак бәягә суыткыч, кер юу машинасы юкмы, дип тә мөрәҗәгать итәләр. Шуңа күрә «Авито»дагы көнкүреш техникасын алып сата башладык. Ватылганын төзәтеп сату да отышлы, – дип сөйләде ул. Өйдәге суыткыч-телевизорлар эшләп кенә торсын!

Эльвира ВӘЛИЕВА

Фикер

Илдус САФИУЛЛИН, икътисад белгече:
– 2023 елның беренче яртысында көнкүреш техникасы базарында берни дә үзгәрмәячәк. Агымдагы елда суыткыч-телевизорларның бәясе сизелерлек артты. Моңа санкцияләр, логистика бозылу да тәэсир итте. Ә халыкның керем дәрәҗәсе шул ук. Өстәвенә, яз башында халык кибетләр ябылудан куркып, өстәөстенә телевизор, кыска дулкынлы мич сатып алды. Өйдә әнә шулар да тора бит әле. Кибет киштәсендәге яңа брендларның сатып алучылар арасында ышаныч яулыйсы да бар. Ә үзебезнең җитештерүчеләргә килгәндә, алар барыбер дөньядагы вазгыятькә бәйле. Чынбарлыкка яраклашу өчен шул ук «Позис»ка да, мәсәлән, вакыт кирәк булачак.

! **Роспотребнадзор белгечләре бездән киткән чит ил көнкүреш техникасы ватылган очракта, аның акчасын ничек кайтарырга икәнен аңлаткан.**

– Җитештерүче товарның куллану вакыты чыкканчы аннан тиешенчә файдалану мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш. Шул рәвешле, теге яки бу юридик зат илдән китте дип кенә, кулланучылар алдындагы бурычлар юкка чыкмый. Җитештерүче товарны техник күзәтү, ремонтлау мөмкинлеген дә тәэмин итәргә тиеш. Ремонт өчен детальләрне техниканың куллану вакыты чыкканчы, ә бу вакыт күрсәтелмәгән очракта – 10 ел, җитештерү каралган. Дөрес, аларны илгә кайтару белән кыенлыклар килеп чыгарга мөмкин. Техниканың гарантия срогы чыкканчы кимчелекләре ачыкланса, кулланучы сыйфатсыз товар өчен акчаны кире кайтаруны кибеттән таләп итә ала.

КЕМНӘРНЕ ЮГАЛТТЫК?

Кызганыч, узып баручы елда югалтулар да күп булды. Бакыйлыкка күчкән шәхесләр арасында танылган әдәбият һәм сәнгать әһелләре дә, галимнәр һәм җәмәгать эшлеклеләре дә шактый. Искә алуыбыз рухларына дога булып барып ирешсен.

ТЕАТР ӘҺЕЛЛӘРЕ:
– Камал театры актрисасы, Татарстанның халык артисты **Раушания Юкачева**;
– Камал театры актеры, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты **Наил Дунаев**;
– Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә театрының элеккеге җитәкчесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Роберт Шаймәрданов**;
– Әлмәт театрының элеккеге җитәкчесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Тамара Халитова**;
– Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты **Феликс Пантюшин**;
– Түбән Кама татар дәүләт театрында эшләгән Татарстанның атказанган артисты **Наил Сәйфетдинов**;
– драматург, Татарстанның Язучылар берлеге әгъзасы **Эсфир Яһудин**;
– Татарстанның халык артисты, Тинчурин театры ветераны **Земфира Досаева**.

ӘДӘБИЯТ ҺӘМ МАТБУГАТ ВӘКИЛЛӘРЕ:
– язучы, журналист, нәшир, Татарстанның Язучылар берлеге әгъзасы **Заһид Мәхмүди**;
– татар язучысы һәм журналист **Ягъсуф Шәфыйков**;
– журналистика ветераны, тел галиме, филология фәннәре докторы, профессор **Илдар Низамов**;
– «Татарстан» радиосы дикторы **Мәрьям Арсланова**;
– матбугат ветераны **Әсгать Сәлахов**;
– журналист **Анна Тарлецкая**;
– журналист **Гафиулла Газиз**;
– язучы **Илдар Хәйруллин**;
– шагыйрь **Рифкать Имаев**;
– шагыйрә **Резедә Вәлиева**;
– шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе **Мансур Шиһапов**.

ДӘҮЛӘТ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ:
– Татарстанның эчке эшләр министрының элеккеге урынбасары, генерал **Андрей Вазанов**;
– Татарстанның атказанган икътисадчысы, Татарстан Президентының социаль-икътисадый мәсьәләләр буенча элеккеге киңәшчесе **Филзә Хәмидуллин**;
– Татарстан эчке эшләр министрының элеккеге урынбасары **Евгений Дәүләтшин**;
– «Лукойл» вице-президенты **Равил Мәганов**;
– Татарстанның элеккеге вице-премьеры **Мансур Хаснуллин**;
– Татарстан Дәүләт Советы Аппараты Хокукый идарәсенең гражданлык законнары бүлеге мөдире **Исрафил Фәттахов**;
– җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче **Фатыйх Сибагатуллин**.

ҖЫР СӘНГАТЕ ВӘКИЛЛӘРЕ:
– җырчы-шагыйрь **Илсур Хөснетдинов**;
– Россиянең халык артисты **Ренат Ибраһимов**;
– җырлар авторы **Фердинант Гайсин**;
– җырлар авторы **Ринат Мөслимов**;
– җырчы **Эльмира Сөләйманова**;
– баянчы, Татарстанның халык артисты **Рамил Курамшин**;
– Самараның «Ялкынлы яшьлек» ансамбле җитәкчесе **Альбина Мәхмүтова**.

ГАЛИМНӘР:
– фольклорчы, сәнгать фәннәре кандидаты **Эльмира Каюмова**;
– әдәбият галиме, шагыйрь, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе **Нурмөхәммәт Хисамов**;
– Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Гуманитар фәннәр академиясе академигы, икътисад фәннәре докторы, профессор **Рифат Исләев**;
– профессор **Гали Даутов**;
– педагогика фәннәре кандидаты, күпсанлы дәреслекләр авторы **Закирә Хәбибуллина**.

РӘССАМНАР:
– Россиянең атказанган, Татарстанның халык рәссамы **Зөфәр Гыймаев**;
– Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, рәссам **Сания Бәхтиярова**;
– Россиянең атказанган рәссамы **Рәшит Госманов**.

vk.com

Бергә-бергә!

Ничек кенә булса булсын,
Кара көннәр артта калсын!
Иске елның яралары
Яңа елда сулу алсын!

Ничек кенә булса булсын,
Адым-адым атлыйк алга!
Язсын Күкләр мәрхәмәте –
Бергә керик Яңа елга.

Ничек кенә булса булсын,
Тәкъдирләрне кабул итик.
Өмет йолдызын сүндерми,
Изге морадларга җитик!

Сания ӘХМӘТҖАНОВА

ТОРМЫШ – ТЕАТР

Елны нинди вакыйгалары белән истә калдырабыз? Кайсы телдән төшмәде? Шәхесләрдән кемнәр эш-гамәлләре белән аерылып торды? Шушы һәм башка сорауларга җавап табу өчен укучыларыбыз арасында сораштыру үткәрдек.

Нәтиҗәдә халык күбрәк Камал театрына йөри, Зифа Кадыйрова китапларын ярата, хәйрия эшләрендә актив катнаша, цифрлы өлкә белән кызыксына дигән нәтиҗә ясадык. Чөнки Татарстан дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин ел шәхесе булып танылды. Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов аннан азга гына калышты. Ел оешмасы дип укучылар «Ярдәм янәшә» хәрәкәтен атадылар. Әлеге номинациядә яңа төзелгән Продюсерлар берлеге һәм пионериягә алмашка килгән Балалар һәм яшьләр хәрәкәте дә бар иде. «Ел китабы» номинациясендә быел китаплары чыккан Рәниф Шәрипов, Фирдүс Гыймалтдинов та бар иде. Әмма укучыларыбыз Зифа Кадыйрова иҗатын якынрак күрде. Укучыларыбыз фикеренчә, елның иң яхшы спектакле – «Мөһаҗирләр», ел проектында исә иң күп тавышны Камал театрының төзеләчәк яңа бинасы җыйды. Анда Җәмигъ мәчете һәм М12 юлы төзелешләре дә бар иде. Кыскасы, тормышыбыз – театр, яшәешебез – Зифа Кадыйрова романы.

КУЯНДА ИКЕ УЙЛАМЫЙЛАР

«Без куян кебек куркак түгел, кыю, аның кебек җитез». Актаныш районының Куян авылы халкының үз холкына бәясе бу. Быел бигрәк тә яшьләр 12 ел элек җиткергән гозерләренең чынга ашуын көтә. Хыяллары – яңа клублы булу. Куянлылар Яңа елны ничек каршыларга җыена?

Авыл артык зур да, кечкенә дә түгел. Монда бүген 95 йортта 252 кеше яши. Клуб, бакча, кибет, медпункт эшли. Элек исә куян фермаларына кадәр булган. Тиресен иләп, бүреген теккәннәр. Авыл халкы мал-туар асрап көн күрә. Эшләргә генә түгел, җырларга, биергә дә оста алар, театр да уйныйлар. Яшьләр арасында авылда калганнар да бар. Быел ике яшь пар гаилә корса, өчесе яңа йортка күчкән. Әнә Рузил Шакиров быел бабасының васыятен үтәп, аның нигезендә йорт җиткезгән.

– Әти дә, бабаларым да авылдан китмәгән, мин дә китмим. Фоат бабам, нигезне сакла, бу йорт сиңа кала, дип әйткән иде. Аның әйткән сүзен җилгә очырмадым. Биш ел элек төзи башлаган йортыбызга күчендек. Нигезебез гомерлек булсын иде. Бакчага өч төп груша утырттым. Улыбыз да, кызыбыз да бар, шөкер. Ир буларак, бурычымны үтәдем. Үзем Актаныш икмәк кабул итү оешмасында эшлим. Киләсе елда сәламәт булып, куян кебек җитезлекне арттырып, куйган планнарны үтәргә иде, – ди 34 яшьлек Рузил Шакиров.

Куян елына дип куянлылар декабрь башында ук әзерләнә башлаган. Авылда 34 ел клуб мөдире булып эшләүче Роза Хәбетдинова әйтүенчә, бер көн буе авылның табигатен, тырыш кешеләрен, куян асраучы хуҗалыкларын видеога төшереп мәш килгәннәр. Авыл имамы Куян тарихы турында сөйләгән, сугышта һәлак булучыларны искә алып, һәйкәлгә чәчәк салганнар. Җигүле атларда Кыш бабай, Кар кызы утырып, авыл урамнарын әйләнгәннәр. Яңа йортка күченүчеләр, чишмәдән су алып кайтып, чәй куйган. Яшьләрнең фикерләрен белешергә дә җай чыккан. Куян асраучы хуҗалыкларның да хәлен белешкәннәр. Алар – икәү. Ганиевлар нәселендә бу шөгыль әтидән улга күчеп бара.

– 20 ел элек олы улыбызның туган көненә куян бүләк иткән идек. Шуннан бирле асрыйбыз. Элек баш саны алтмышка кадәр җитә иде. Хәзер 15–20ләп кенә. Дөресрәге, оныклар өчен тотабыз. Алар ишегалдында алар белән уйный, күрше балалары да җыела. Улыбыз Фәнил башка чыкты, аңа да куян бирдек. Студент улыбыз Рифат Чыршы бәйрәменә лотереяга куян бүләк итте, – ди биш бала анасы Фәүзия апа Ганиева.

Озынколаклар да авылга юлны онытып бетерми: кышларын бакчадагы алмагачларны кимереп китәләр. Тик куянлылар моңа аптырамый: ак карда эзләрен күрү үзе бер кызык. Бу бит куяннар белән бәйләнеш өзелми дигән сүз. Авылда Куян елы тынычлык алып килсен дигән теләктә яшиләр.

Зурлар һәм кечкенәләр хыялы

Узган ел Биектау районындагы Шышшиек авылына Яңа ел бәйрәменә кайту Әскәровларга 10 мең сумга төшкән. Өч чакрым юлны чистарттыру өчен киткән чыгым бу. Быел кечкенә һәм зур авылларда бәйрәмне ничек каршы алырга җыеналар? «ВТ» хәбәрчесе анда яшәүчеләрнең хәлләрен белеште.

Шышшиек авылында ике хуҗалыкта гына кыш чыгалар. Бу – дүрт кеше дигән сүз. Алары да – туганнар. Кайчак «дачник»лар да кайткалый. Монда кыш көне юлны ачмыйлар, кирәк-яракка күрше авыл кибетенә чаңгыда йөриләр.

– Узган ел бу вакытта бер генә түгел, ике чыршы бизәгән идем. Быел илдәге вазгыять турында күп уйлагангамы, нигәдер күңел үсми. Шулай да капка төбендәге чыршыга уенчыклар элдем. Узган ел балалар кунакка кайтты. Урамга чыгып биедек, салютлар аттырган идек. Быел улыбызның юл ачтырыр өчен аның кадәр акчасы юк. Шәһәрдә генә бәйрәм итмәкчеләр. Тәмле ризыклар пешерәсе булыр инде. Кибеткә барып, тәм-томын, мандаринын алып кайтырга кирәк, – ди Гөлсинә апа Әскәрова.

Икенче йортта яшәүче Илсөя Бикбаева әйтүенчә, авыл кешеләре киләсе елда юл булмасмы, дип көтә. Иң зур хыяллары шул.

– Авыл башында быел бер эшмәкәр ферма төзеде. Бу арада юлны шунда кадәр булса да чистартканнар иде, хәзергесе ничектер, белмим. Әле салкын тиеп чирләп ятам. Юл булмагач, табиб та чакыртып булмый бит. Чүпләрне җыю өчен берәр урын кирәк. Ташландык йортларның базларын тутырдык инде. Хәзер балалар кайтканда чүпне шәһәргә бирергә җибәрәбез. Менә шундыйрак хәлләр. Яңа ел кәефе әлегә сизелми. Чыршы ботаклары исен иснәргә урамга чыгабыз үзе, – ди Илсөя ханым.

Кечкенә авыллар юл көткәндә, зурлары нинди өмет-хыяллар белән яши?

Арча районының Яңа Кенәр авылында 2100 тирәсе кеше яши, 610 хуҗалык исәпләнә. Моңа кадәр Яңа елны шау-гөр килеп уздырган булсалар, быел халык күңелендә – башка хис. Ике сүзнең берендә: «Егетләр хәрби операциядә булганда, безгә күңел ачу килешмәс», – дип читенсенәләр икән.

– Кәефләр башка еллардагы кебек түгел. Әмма балаларга бәйрәм оештырмыйча да булмый. Бүген мәктәп, бакчаларда Чыршы бәйрәме уза, аннан клубта булачак. Моңарчы һәр оешма, мәш килеп, кар сыннары ясаса, быел андый омтылу да юк. Тик шулай да иң матур сын ясаучы хуҗалыклар һәм оешмаларны билгеләячәкбез. Бүләк – иганәчеләрдән, – ди җирлек башлыгы Әгъзам Гайфуллин.

Мәдәният йорты каршында бер чыршы бизәсәләр, икенчесенең утлары тиздән авыл уртасында «Ленин бакчасы» паркында кабыначак. Гыйнвар аенда оешмалар биш көн дәвамында кичен шунда концерт күрсәтәчәк. Әхтәм абый җиккән атка утырып, мәдәният хезмәткәрләре авылны ураган инде. Чанага сабыйлар да утырган. Кемдер – Убырлы, Куян, кемдер башка җәнлекләр булып киенгән. Басуга чыгып, Яңа елны каршы алганнар һәм кызыклы кино төшергәннәр. Менә шуны бәйрәм көнне авыл халкына да тәкъдим итәчәкләр. Лотерея да уйнатылачак. Самавыр куеп, коймаклар пешереп, чәй эчү теләге дә юк түгел. Авылда салют аттыру тыелган. Моның өчен читтә махсус урын булдырганнар.

Хәрби операциягә киткән егетләрне дә онытмый авылдашлары. Бергәләшеп мичләр ясап, җылы киемнәр, көрәк, пычкы кебек барлык кирәк-яракларны туплап озатканнар. Бу эшне әфганчы Рашат Салихҗанов оештырса, Ленар Гарипов ике тапкыр «ГАЗель» белән ярдәмне иярләренә илтеп тапшырган. Яңа елдан соң тагын юлга кузгалачаклар. Авыл халкы егетләргә күчтәнәчен әзерләгән инде.

Сәрия МИФТАХОВА

Яхшыга юрыйк!

Куян елында безне ни көтә? Бу хакта күрәзәчеләрнең дә фикерен белештек. Ышану-ышанмау – һәркемнең үз эше.

Алсу ГАЗИМҖАНОВА, «Битва экстрасенсов» проекты җиңүчесе:

– Узып баручы ел җиңел булмады. Үзем дә аны авыр кичердем. Ә менә киләсе ел тыныч булырга охшаган. Куян елы – гаилә кору, мөнәсәбәтләрне рәсмиләштерү өчен әйбәт ел. Торак бәяләре шактыйга төшәчәк. Кулында акчасы булганнарга күчемсез милек алырга киңәш итәм. Күңел тынычлык тели. Узган ел мин хәрби конфликтлар буласын әйткән идем. Быел аларның көтелмәгәндә яхшы якка борылып аласын күрәм. Уртак сөйләшүләр барысын да хәл итәчәк.

Куян елында кеше үзенә тынычлык табачак. Өйләрендә куян тотучылар да артып китәр. Узган ел иткә бәя артуын әйткән идем. Әкренләп аны кулланучылар кимеячәк. Медицина тагын да алга китәчәк. Бездә бик катлаулы операцияләрне ясый башлаячаклар. Киләсе елда күп кешеләр шәхесен үстерү өстендә эшләвен дәвам иттерәчәк. Укырга омтылучылар күп булачак. Коронавируска килгәндә, 2023 елда ул бөтенләй телгә алынмаячак. Аның урынына сезонлы чирләр калачак. Кулланыштан кәгазь китә. Бу акчага да бәйле булачак. Бик күп хезмәтләр электронлашачак. Соңгы вакыйгалар безне тормышның кадерен белергә өйрәтте. Киләсе елда да бер-беребезгә яхшы мөнәсәбәттә булып яшәсәк иде.

Фавазилә САГАЕВА, халык күрәзәчесе (Башкортстан):

– Юлбарыс елы авыр булды. Әлеге җәнлек корбаннар ярата. Шуңа да күп кенә якыннарыбызны югалттык. Куян елы исә яхшы хәбәрләр китерәчәк. Куян – йомшак, иркә, араларны җайлаучы хайван. Халыкны сөендерәсем килә: ни генә булса да, тыныч көннәргә ерак калмады. Җәйгә таба илгә иминлек киләчәк. Көнбатышта яшәүчеләргә кыен булачак. Алар яхшы тормышта яшәргә иярләнеп беткән иделәр. Авырлык алдында калырлар. Доллар чүпкә әйләнеп калачак. Аның каравы евро үсәчәк. Тагын шунысы бар: элек араны өзгән чит илләр безнең белән дуслашачак.

Давыллар, куркыныч яңгырлар, табигать бәла-казалары булмаячак. Ковид бетте дисәк тә, йогышлы авырулар баш күтәрәчәк. Киләсе елда балалар күп авырырга мөмкин. Әмма бу чир зурларга тимәячәк. Бала дигәннән, күп кенә гаиләләрдә өченче сабый туачак. Шул ук вакытта бәби сөя алмаучылар да артачак. Бу кешеләрнең компьютер янында утыруы, аз хәрәкәтләнүенә бәйле.

Авыл хуҗалыгына килгәндә, уңыш әллә ни сөендермәс. Бәрәңге начар булачак.

vk.com

kamalteatr.ru

ИЛ БЕЛӘН БЕРГӘ

Без – зур үзгәрешләр алдында. Узып баручы каршылыклы елга әдәбият-сәнгать әһелләре әнә шундый бәя бирә. Ел башы Камал театрының яңа бинасы проекты тирәсендәге бәхәсләр белән башланып китсә, аңа яңадан-яңа дулкынланулар өстәлеп кенә торды. Без үз юлыбызны эзләүгә керешергә торганда, Көнбатышта рус әдәбияты тыелды, кино сәнгате зур фестивальләргә чыга алмады, мәдәният исә Россия кануннарына яраклаштырыла башлады. Аның җимешен без әле алдагы елларда татырбыз. Елның төп казанышлары нидән гыйбарәт соң? Шуларны барлыйк әле.

Ел төзелеше

Февральдә Камал театрының яңа бинасы проекты тәкъдим ителсә, апрельдә Казанда төзеләчәк Җәмигъ мәчетенең урыны билгеле булды. Шул уруындагы «Кырлай» паркының Яңа Савин районындагы Җиңү паркы янына күченәчәге игълан ителде. Яңа урынга балаларны хәзердән иялаштерәләр инде. Җиңү паркы белән «Парк Хаус» сәүдә үзәге арасында боз шәһәрчеге калкып чыкты. Быелгы төзекләндерүләргә килгәндә, «Мир» кинотеатры залы матурайды. Казанның «Салават Күпере» торак комплексы һәм Әлмәт шәһәре яңа парклы булды.

Театрлар

Бу өлкәдә тамашачы өчен чын мәгънәсендә көрәшергә туры килә. Пандемия чорында өйдә утырырга күнеккән тамашачыны ничек тә яңадан театрга иялаштерергә, яңа алымнар, формалар эзләргә туры килә. Бу җәһәттән Тинчурин театры актив булды. Ел әйләнә театр буйлап экскурсияләр оештырудан тыш, төрле тәҗрибәләргә алынды. Дөрес, аның кайсы кабул ителде, кайсы юк. «Умай» лабораториясенең «Ал яулык, зәңгәр шәл»е тамашачы күңеленә ятып бетмәде. Шушы ук спектакль, театрның матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, «Алтын битлек» конкурсында мактауга лаек булган. Чакырылган режиссер Сәрдәр Таһировский куйган «Хан кызы Турандык» кыюлыгы белән истә калды. Ә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан кабат яңартылган «Кара пулат» операсы халыкара «Алтын Трезини» конкурсында дипломант булган. Киләсе елда театр «Идегәй» дастанын тәкъдим итәргә җыена. Шулай ук Ркаил Зәйдулла әсәре буенча «Ашина» спектакле әзерләнә. Саллы әсәрләр белән тинчуриннылар театр оешуның 90 еллыгын каршы алырга әзерләнә.

Тамашачы арасында фестивальчеләр булып танылган Әлмәт театрында хәлләр ничек? Театр директоры Фәридә Исмәгыйлова әйтүенчә, ел уңышлы булган:

– Театрга соңгы өч ел, пандемияне дә кертеп, сынау булды. Әмма ничек кенә булса да, бөтен өлкәләр кебек үк мәдәният тармагы да эшли, алга бара. Быел премьералар күп чыкты. Россия күләмендә ниндидер дулкынланулар, талантларның чит илләргә китүе күзәтелсә дә, Татарстанда бу җәһәттән тыныч, репертуарлар да тотрыклы. Бу ел Әлмәт театры өчен уңышлы: дәүләт заданиесен үтәдек, бер-бер артлы яхшы премьералар чыгардык. Ел башындагы «Тантана»да да бөтен уңышны Әлмәт театры җыеп алды бит. «Җил артыннан» (режиссеры – Камил Тукаев) спектаклен прокатка чыгардык дип тә әйтә алабыз. Аны 25 тапкыр уйнадык, өстәвенә фестивальләрдә җиңү яуладык. Режиссер Айдар Җаббаров «Ул әле өйләнмәгән иде» спектаклен куйды, артистлар өчен бу үзе бер мәктәп булды. Зөлфәт Хәким әсәре буенча куелган «Ана җыры» бик уңышлы бара. Моның өстенә ел дәвамында 10 фестивальдә катнаштык. Әмма иң зур уңыш – труппаның исән-сау булуы, репертуарның тотрыклылыгы. Барыбыз да исән-сау булыйк.

Буа театры җитәкчесе Раил Садриев фикеренчә, мәдәният – ил сәясәтенең аерылгысыз өлеше:

– Мәдәният, башка тармаклар кебек үк, үзгәрешләр чорына керде. Яңа төрле, халык таләбенә туры килгән спектакльләр кирәк, эзләнергә, уйланырга кирәк. Әле без – мәдәнияттә үзгәрешләрнең башында гына. Ник дигәндә, бер калыпка кергән иҗатка кызыксыну югала, бу – котылгысыз процесс. Дөнья күләмендә үзгәрешләр барганда, башкача булмый да. Чөнки авыр чакта мәдәният һәрвакыт алгы планга чыккан. Әлегә, башка төсләрнең барлыгын онытмыйча, ак белән караны аеру процедурасы башланырга тора. Бу җәһәттән без – шул юлда. «Шобага», «Фатыйма», «Дәрвиш» – хәзерге көн таләбенә туры китереп куелган. Җыеп әйткәндә, илнең сәясәтеннән, икътисадыннан бернәрсәне дә аерып булмаган шикелле, сәнгатьне дә аерып булмый. Шуңа безнең алда зур бурычлар тора. «Пушкин картасы»н гына алыйк. Әле без аның да яртысын гына файдалана алдык. Бу бит – зур сумма! Шуңа әле безнең эшлисе эшләр бик күп. Ә эшләп була! Безнең буын киләчәккә юл күрсәтү өчен юлга сузылып ятарга әзер. Бер караганда, мин тылсымлы заманда яшибез дип уйлыйм. Чөнки нәрсә уйлыйсың – шул алдыңа килә, нәрсә телисең – шул килеп чыга. 1995 елда үзгәрешләр кичердем, шул чакта кыйбламны үзгәрткән идем. Шуннан бирле туплап килгән уйларымны «Дәрвиш» спектаклендә җиткерә алдым дип уйлыйм.

> Әдәбиятта тыюларга килгәндә, аны бер юләрлек кебек кабул итәм. Тормышта иң начар әйбер – артыгын кылану. Ул – гөнаһ. Хәзерге заманда бу хис бигрәк тә алгы планга чыга. Кайдандыр куштырнаклар әчендәге патриотлар килеп чыга һәм артыгын кыланып ташлый.

Дөрес, вакыт барысын да үз урынына куячак. Бу ярамый, моны тыярга дигән кешеләрнең дөрес эшләмәгәнлекләре утыз елдан килеп чыгарга мөмкин. Шуның өчен һәр кешенең эчендә компас булырга тиеш. Безнең буында ул компас бар. Чөнки без совет заманын да күргән, туксанынчы еллар азгынлыгында да югалмаган. Без әйбәт белән әйбәт түгелне аералый беләбез.

Авылдагы профессиональ театрыбыз – Әтнә театрында да быел премьералар шактый булды. Алар арасында театраль гурманнар өчен булган «Ак пароход» спектакле дә, киң катлау тамашачыга адресланган «Хыял йорты», «Кар астында кайнар чишмә» кебек спектакльләр дә бар. Моннан тыш театр, Гомәр Мәрданов исемен мәңгеләштерү йөзеннән, театраль фестиваль оештырган. Нәтиҗәдә әлеге фестивальдә җиңүчеләр театр училищесына укырга керергә җыена.

Төп театр Камалда да үзгәрешләр шактый. Беренчедән «Шәрык клубы» активлашты. Көн саен чаралар уза, алар арасында лекцияләр, спектакльләр күрсәтелә, балалар өчен тамашалар оештырыла. Нинди спектакльләр дигәндә, «Бичара кыз», «Гөлҗамал», «Безнең шәһәрнең серләре». Күргәнегезчә, классик әсәрләр. Төп бина хәлләренә килгәндә, 4 премьера чыгарылды. Алар арасыннан «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» спектакле баш режиссерның юбилеена багышланды.

Әдәбият

Без – укымышлы халык, дип әйтергә яратабыз бит инде. Бер караганда, милли китапханә саннары моны раслый да. Китапханәнең матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, ел дәвамында 322426 китап укырга алынган. Алар арасында уникаль китаплар – 30 мең тирәсе. Бер китапны ел дәвамында уртача 11 мәртәбә өйгә укырга алалар икән. Иң укылган китапларга килгәндә, беренче урында рус әдәбияты һәм унлыкның башында Гүзәл Яхинаның «Эшелон на Самарканд» романы тора. Иң укылышлы татар әдәбияты – Әлфия Ситдыйкованың «Дөнья тәгәрмәче», Рифат Сәлахның «Ак фәрештә», Сәмига Сәүбанованың «Кырау суккан алмагач» китаплары. Иң күп укылган китаплар арасында, кызганыч, татарчалар юк. Иң күп укылган үсмерләр китаплары арасында да андыйлар күренми. Иң популяр фәнни-популяр әдәбият арасында татар китаплары юклыгын сез инде болай да төшенгәнсездер.

> Татарстан китап нәшриятыннан иң күп сатылган китаплар исемлеген алдык. Болар – рус телендә чыккан «Шүрәле», русча татар халык әкиятләре һәм «Секреты татарской кухни» китаплары. Аңлашылганча, бар да рус телендә. Татар әдәби китаплары арасында иң күп сатылганы – Әлфия Ситдыйкованың «Таш тамыры», Нәбирә Гыйматдинованың «Үлмәс» романы. Сатылган дәнәләрне чагыштырсак, татар китаплары русчалардан бик күпкә калыша. Ни кызганыч, татар китабын укучылар саны елдан-ел зур саннарда кими.

Каләм әһелләре агымдагы елны нинди кәеф белән озата соң? Шагыйрә Гөлүсә Батталова аны балигъ булу елы дип атый:

– Нәрсә уйлаганын әйтергә, аны шигырь юлларына төшерергә һәм аны укучылары белән тиз арада бүлешергә өйрәнгән кешегә бу ел җиңел булмады. Ул күңелемдә авыр кайтаваз алды, иҗатым сөрлегеп калды. Әмма шул ук вакытта бу ел бик күп нәрсәләргә төшенергә ярдәм итте. Мин бу елга кадәр дөньяга алсу күзлектән караган кызчык булганмын икән. Быел шагыйрә буларак балигъ булдым. Ул эзсез үтмәс, иртәме-соңмы иҗатымда чагылыр.

Быел гыйбрәтле күзәтүләр ясадым. Кайбер кешеләрне яңа яктан ачтым. Кайбер ачышлар көтелмәгәнчә булды. Кайвакытта сүзең һәм гамәлләрең белән дөньяны үзгәртә алмасаң да, кешеләргә рухи терәк булырга кирәклегенә төшендем. Бу минем өчен кайчак зур җиңү булды. Дөнья ак һәм кара төстә генә була алмый шул. Ә гомумән әдәбият дөньясына күз салсак, минем өчен табышлар күп булды. Кызыклы китаплар чыкты, бу җәһәттән мин әдәби бәйгеләргә бик рәхмәтле. Алар язучыларга стимул бирә, китап укырга яратучыга исә сыйфатлы әсәрләр бүләк итә. Рүзәл Мөхәммәтшинның «Лаләләр» хикәясен, Зөлфәт Хәкимнең «Бер сәгатьтә ничә мизгел бар?» романын быелгы табышларым дип саныйм. Конкурс минем үземә дә иҗатка этәргеч бирә. Җиңүдә түгел бит хикмәт, иҗат әһелләрен активлаштыруда.

Эстрада

Ел саен уза торган фестивальләргә тукталып тормыйча, эстрададагы төп кәефкә тукталыйк. Алгы планга игелек чыкты, дисәк, ялгышмабыз. Артистлар гуманитар ярдәм хәрәкәтенә актив кушылды. Хәйрия чаралары активлашты. Бу җәһәттән Фирдүс Тямаев, Илсөя Бәдретдинова, Раяз Фасыйхов үрнәк күрсәтте. Без – шундый халык инде: авырлык килсә, арбага җигелебрәк тартабыз. Тик менә татар телен ничек саклап калырга? Тел булмаса, әдәбият-сәнгатьнең дә кирәге калмаячак бит.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

< Дәвамы. Башы 16 декабрь санында

НУРИХАН ФӘТТАХ

КИЧҮ

(РОМАННАН ӨЗЕК)

«Вәсби абый»ны укучылар түгел, укытучылар әйтсә, Василий Михайлович шулай ук һәр очракта төзәтергә, кисәтергә кирәк дип исәпли иде. Мондый чакта ул гадәттә: «Нинди Мулла, нинди Хан инде ул, Замила Галиахметовна?! Мин инде сезне предупреждать иттем… Эндәшмәгез миңа шул… извините за выражение… авыл хатыннары кебек», – дия торган иде.

Мәктәп директоры вазыйфасыннан тыш Василий Михайлович югары классларда физика, математика фәннәре укыта иде. Укытучы буларак, ул әллә ни мактарлык түгел, ләкин директор буларак бөтен районда, хәтта бөтен республикада иң булдыклылардан санала иде. Аның бөтен булдыклылыгы исә үзенә буйсынган һәркемне кулында кысып тотуга, югарыдан килгән күрсәтмәләрне бернинди каршылыксыз үтәүгә кайтып кала иде. Иң мөһиме – ул район җитәкчеләренең берсе белән дә телгә-тешкә килмәскә тырыша иде.

Район җитәкчеләре белән килешеп яшәсә дә, мәктәптә, үз коллективында аны бөтенләй диярлек хөрмәт итмәделәр. Берәүләр аны ачыктан-ачык дошман күрделәр, икенче берәүләр дошманлыкларын сиздермәскә тырыштылар. Мондый мөнәсәбәтнең сәбәбе, барыннан да элек, Василий Михайловичның үтә коры һәм формалист кеше булуына кайтып кала иде бугай. Үзе физика-математика укытучысы, хатыны химия укытучысы булганга күрә, ахрысы, аның өчен дөньяда бары физика-математика да химия генә игътибарга лаек фәннәр исәпләнелә иде. Аннары, әлбәттә, урыс теле.

Бу, билгеле, Василий Михайловичның шәхси карашы гына да түгел, бу бөтен илдә хөкем сөргән гомуми политика басымы нәтиҗәсендә барлыкка килгән мәҗбүрият иде. Менә шушы гомуми политик карашларны башкаларга көчләп тагарга тиеш булганга, Василий Михайловичның иң ачуын китергәне, эчен пошырып, үртәп торганы татар теле белән татар әдәбияты иде. Тумыштан татар булганга ук, билгеле, үзенең татарлыгын да оныта алмый, хәтта аны онытырга да теләми, шул ук вакытта, коммунист һәм җитәкче буларак, татарлыкны ул онытырга, аңа каршы килергә, аны дошман күрергә тиеш сыман иде.

Габделхәйнең шигырь белән пычранып утыруын күргәч, аның күңелендә үзеннән-үзе яшьлек хатирәләре калкып чыкты. Бит кайчандыр ул да яшь булды, киләчәктә нәрсәдер кырмакчы булып, очынып-тилереп йөрде. Ул чакта әле хатын да, балалар да юк, җилкәңә таудай булып өелгән җаваплылык тойгысы да юк. Бары дәртле яшьлек бар да тау-тау бәхетләр вәгъдә иткән матур киләчәк кенә бар. Хәзер инде яшьлек тә, дуслар-иптәшләр дә, хәтта киләчәк тә юк. Киләчәк ул беркайчан да булмады бугай. «Киләчәк» дигән вакыт инде күптән килде, бары тик ерактан шундый матур булып күренгән бәхет тә, байлык та, дан-шөһрәт тә кайдадыр качып-посып калды.

Да, бар иде заманалар. Иң гаҗәбе шул: Вәсби Алдынский да, ягъни яшь чактагы Василий Михайлович та Мухутдинов кебек шигырь белән җенләнә иде. Да, да, рабфакта укыганда ул чын-чынлап шагыйрь булам дип тилереп йөрде. Начар да язмады. Рифмалары матур, килешле чыга торган иде. Ул вакытта күпләргә шигырь җене кагылган иде. Әле анда, әле монда шаулатып әдәби кичәләр үткәрәләр, бәхәсләшәләр… талашалар. Эх!..

Берзаман ул иптәшләре арасында талантлы шагыйрь саналып йөрде. Да, талантлы. Заманалар үзгәреп китмәсә, Вәсби Алдынскийдан менә дигән шагыйрь чыгар иде, мужыт. Сәхип әл-Назаридан, хәтта Такташтан, Кутуйдан да талантлырак шагыйрь чыгар иде. Но, однако, менә чыкмады. Бөтен эшне замана бозды. Бозылды замана. Юк, Вәсби Алдынскийдан шагыйрь дә, беркем дә чыкмады. Шагыйрь булу, бөек кеше булу турындагы хыял «тормыш кыясы»на бәрелеп чәлпәрәмә килде. Дәрт сүнде, күңел суынды, күңелдә бары ачу, үртәлү дә курку гына торып калды.

Рабфакта укыганда аның шигырьләре сирәк кенә булса да гәзитләрдә, журналларда басылды. Бер елны ул, тырышып-тырмашып йөри торгач, аерым җыентык чыгару бәхетенә иреште. Шигырь җыентыгы. Китап. Вәсби Алдынскийның түбәсе күккә тиде. Китапны үз күзләре белән күреп, үз кулында тотып карагач, ул берничә көн кая басканын белми йөрде. Унысы бер белән калынлыгындагы китапларын кибеттән күпләп сатып алды да барлык таныш кызларына, дус-ишләренә бүләк итеп йөрде.

Шулай куанычтан исереп, кая басканын белми йөргән көннәрнең берсендә «Кояшлы иртә» исемле җыентыкка рецензия басылып чыкты. «Өч тиенлек шигырьләр» дип аталган рецензия азагына Гадел Тәрәшле дигән имза куелган иде. Да, Гадел Тәрәшле. Көнчел, ялагай, икейөзле дуңгыз. Дуңгызның да дуңгызы. Кешедә бары начар якларны гына күрә торган, тирестә тибенә торган тавык кебек, шуннан үзенә тәм таба торган бер бәндә.

Әлеге рецензиядән соң Вәсби Алдынский шактый вакыт исенә-акылына килә алмады. Исенә-акылына килгән иде, шигырь язуга да, әдәбиятка да кинәт кенә күңеле сүрелеп куйды. Гадел Тәрәшленең кайбер сүзләре аңа дөрес сыман тоелды. Моны бары үз-үзенә таныйсы гына килмәде. Әкренләп ул шигырь язудан гына түгел, әдәбияттан һәм шигырьчә иптәшләреннән дә читләшә башлады. Шулай итеп, әдәбият арбасына тагылып китә язган Вәсби Алдынский таулы-ташлы юлда очраган беренче дыңгырдыкта ук, тәгәрмәчтән чәчрәп калган каты ләпек кебек читкә чәчрәп, төшеп калды. И шуның белән котылып та калды. Утыз җиденче, утыз сигезенче елларда аның шигырьчә иптәшләре, дус-ишләре, таныш-белешләре бер-бер артлы кулга алынганда, ул инде әдәбият дөньясыннан бик еракта иде. Гадел Тәрәшледән дә усалрак, кансызрак тәнкыйтьчеләр аның «өч тиенлек» шигырьләр китабына нишләптер игътибар итмәделәр. Шомлы, дәһшәтле елларда Яңавыл кирпеч заводында кара эшче булып эшләгән Вәсби Суяргулов барысын да белеп-ишетеп торды.

Кирпеч заводына ул тикмәгә генә кермәде. Нәрсә буласын алдан сизенгән сыман, укытучылыгын ташлап, монда ул үз теләге белән керде. Барлык тимерьюлчылар кебек, кирпеч заводы эшчеләре начар яшәмиләр иде. Тимерьюлчыларның ашау-эчү дә яхшы, кием-салымга да мохтаҗлык юк. Тимерьюлчыга һәртөрле талон бирелә. Аларның магазиннары аерым, мәктәпләре, клублары аерым, хәтта икмәк заводы да, электр станциясе дә – барысы да аерым, барысы да аларныкы. Тирә-яктагы авыл халкы, Яңавылның ярлы-ябагае черек бәрәңге ашап шешенгәндә, тимер юлчылар пох! итеп яшәделәр. Вәсби Суяргулов та бернинди мохтаҗлык күрмәде. Дөрес, монда ул үзен һәрвакыт качкын итеп, яшеренеп ятучы итеп тойды. Кемдер аның элекке эшләрен белеп алыр да, тиешле җиргә барып әйтер һәм көтмәгәндә тиешле җиргә алып та китәрләр сыман тоелды. Кайчан алып китәрләр – төнләме, таң алдыннанмы, әллә көпә-көндез эш вакытындамы, аның өчен бөтен мәсьәлә шуңа кайтып калды.

Шул рәвешчә куркыныч утыз җиденче, утыз сигезенче еллар да узып китте. Кулга алулар турында бик үк ишетелми башлады. Сугыш башланыр алдыннан Вәсби Алдынский тәмам тынычланып калды. Аллага шөкер, исән калды, ахрысы. Сугыш башлангач исә бөтенләй икенче борчулар китте. Да, уйласаң, чәчләр үрә торырлык. Күрде мескен башлар.

Коридордан шыгырт-шыгырт атлап барганда Василий Михайлович, әйтерсең берни күрмәде. Кабинет ишеге алдында туктап, гадәтләнгән бер хәрәкәт белән кесәсеннән ачкыч чыгарды да ашыкмыйча гына йозакны ачты һәм, үз артыннан ишекне ябып, кабинетына керде. Директорның шулай берни әйтмичә кабинетына кереп китүе, җитмәсә, ишекне шапылдатып ябып куюы Габделхәйгә гаҗәбрәк тоелды. «Үзе чакырды, үзе артына борылып та карамады», – дип уйлады ул, хәтере калып. Нишләргә белми көтеп торгандай иткәч, кыюсыз гына ишек шакыды.

– Да! – диде эчтән Василий Михайлович, «керегез» дигәнне аңлатып.

Габделхәй керде, түргәрәк узды, бернинди япмасы булмаган озын шәрә өстәлнең бер кырыенда тукталып калды. Василий Михайлович өстәл тартмасын ачып бик игътибар белән аннан нидер эзләргә тотынды. Ниһаять, ул кирәкле әйберен тапты, өстәл тартмасын кире ябып куйды, бикләде дә башын калкытты һәм ике куллап иягенә таянды.

– Беләсезме, ник чакырдым мин сезне?.. – диде ул, бераз көттереп. – Шигырегезне күргәч, исемә төште… Бер серьезно сөйләшергә кирәк сезнең белән. Сез – безнең иң алдынгы, талантлы укучыбыз, Мухутдинов…

Габделхәй үзенең алдынгы, талантлы укучы икәнлеген белә иде, ләкин аның бу турыда беркемгә кычкырып әйткәне дә, сиздергәне дә юк иде шикелле. Ул моны сер сыман итеп бары күңелендә генә саклый иде. Үзе сер итеп тоткан яшерен нәрсәне чит кеше авызыннан – мактауга саран директор авызыннан ишеткәч, аның өчен бу көтелмәгән яңалык булып тоелды. Шатлыктан йөрәге җилкенеп куйды. Шулай да көтелмәгән шатлык тойгысы ташып чыкмасын өчен, тыелыбрак торырга кирәк тапты. Чынында ул Василий Михайловичның моннан да зуррак, куанычлырак хәбәр әйтүен көтте. Директорның өстәл тартмасында нидер эзләве дә аңа тикмәгә генә түгелдер шикелле тоелды. «Медаль турында әйтмәкче була», – дип уйлады ул шундук үзалдына. Ләкин нишләп шулкадәр көттерә, ялындыра соң ул? Медальнең алтыны булмады, көмеш кенә булды, дип әйтмәкче була микәнни соң?

Василий Михайлович тагын күпмедер көттереп торгандай итте дә әкрен генә сүз башлады:

– Ладно, унны бетердегез, аттестат алдыгыз – дальше нишләргә, кая китәргә исәп? – диде ул, дәрес сорагандагы кебек.

– Ныклап уйлаган юк әле, Василий Михайлович, – диде Габделхәй, теләр-теләмәс кенә.

Ул ялганлады һәм шул ук вакытта ялганламады да. Ул үзен шагыйрь булырга, ниндидер бөек кеше булырга тиеш дип исәпләде. Моңа инде ул күптән күнеккән иде, шуңа күрә бу яшерен хыялының кайчан да булса тормышка ашачагына әз генә дә шикләнми иде. Ләкин, никадәр гаҗәп булмасын, шушы көнгә кадәр әле ул киләчәктә нишләргә тиешлеге турында да, ничек итеп хыялын тормышка ашырачагы турында да белми иде. Бу турыда кем белән булса да фикер алышырга аның кыюлыгы җитмәде. Укытучылар исә үзләре белеп аннан берни сорашмадылар. Алар, гомумән, аның киләчәге белән дә, хыяллары-ниләре белән дә кызыксынмадылар. Алар бары үз эшләренә төшкән бурычларын гына үтәделәр: дәрес укыттылар, дәрес сорадылар, билге куйдылар, кайчагында саран гына мактау сүзләре әйттеләр, кайчагында шелтә белдерделәр. Әгәр дә мәгәр Мухутдинов Габделхәй мәктәптә «иң алдынгы, талантлы» укучы булмаса, Василий Михайлович, бәлки, аны үз кабинетына чакырып та тормаган булыр иде һәм «алдынгы, талантлы» булмаган бик күп укучыларны монарчы кулларына шыгырдавык кәгазь тоттырып, дүрт ягың кыйбла дигәндәй озатып калган кебек, аны да шулай озатып калу ягын карар иде.

– Шагыйрь булыргамы исәп, Мухутдинов? – диде директор, көлемсерәгәндәй итеп.

– Шулай инде, Василий Михайлович, – диде Габделхәй, кызарынып. – Сез бит беләсез… әдәбиятны яратам… шигырь язам.

– М-да. Однако, сез физиканы да яратасыз! – диде Василий Михайлович.

– Әдәбиятны ныграк яратам, – диде үзсүзле Габделхәй.

– Нәрсә яратканлыгыгызны сез әле үзегез дә рәтләп белмисез, Мухутдинов, – диде директор, шактый коры итеп.

Габделхәйгә бу бик сәер тоелды. Үзенең нәрсә яратканын үзе дә белмәскә шулкадәр аңгыра микәнни соң ул? «Алдынгы, талантлы» укучы шулай аңгыра булырга тиеш микәнни?! Шулай да, ул эндәшми калды. Василий Михайлович белән бәхәсләшү, нәрсәгә булса да аны ышандырырга тырышу, гомумән, читен нәрсә иде.

– Сез әле яшь – күп нәрсәне аңлап та җитмисез, – диде директор, кырыслыгын йомшарта төшеп. – Яшь чакта яраткан нәрсәң соңыннан онытыла. Но кайчакта шулай да була: акыл кергәч, карашлар, теләкләр үзгәрә, бөтен нәрсәнең асты өскә килә. Киләчәктә шулай булмасын өчен, сезнең яшьтә олылар сүзенә колак салу мишәйт итми. Сезгә караганда мин күбрәк яшәгән, күбрәк күргән. Тормыш тәҗрибәсе дә җитәрлек, Аллага шөкер. Бишектәге бала бишкә төрләнә, диләр картлар. Була бит шулай? Була!

– Буладыр, – диде Габделхәй.

– Секрет итеп мин сезгә шуны әйтим: – диде Василий Михайлович, бөтенләй үз кеше булып. – Һәрбер талантлы кеше яшь чагында шигырь яза. Шигырь язу гына шагыйрь булу дигән сүз түгел. Беләсезме, сезнең кебек чакта мин дә шигырь яздым.

– Сез дә?! – диде Габделхәй, исе китеп.

Василий Михайлович эндәшмичәрәк утырды.

– Да, Мухутдинов, мин дә, – диде анары дәртсез, шыгырдавык бер тавыш белән. – Как это не удивительно, яздым. Сезне мактаган кебек, мине дә мактадылар, шигырьләремне газеталарда, журналларда бастылар. Даже бер китап та чыгардым. Но мин вакытында акылга утыра белдем. Шигырьгә дә, әдәбиятка да кул селтәдем. Хәзер менә шуның өчен сөенеп бетә алмыйм.

Ахыры бар >

БЕЗДӘН СЕЗГӘ – 3 БҮЛӘК

1 ЯЗЫЛ!
2023 елның беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына языл

2 КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!

89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘККӘ
1. Суыткыч.
2. Микродулкынлы мич.
3. Мультиварка.

П2435
җомга саны
512 сум 70 тиен

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
1143 сум 96 тиен

Акция 2022 елның 26 октябреннән башлап 2023 елның 20 гыйнварына кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru

16+

реклама

Әз-мәз мәзәк

– Әни, Кыш бабай һәр чыршы астына бүләк куямы?
– Әйе, улым.
– Ә ник без алайса бер генә чыршы куябыз?

* * *

Балыкчылар сөйләгәннәрдән:
– Бу балыкны көймәгә тартып чыгаргач, Идел ярты метрга түбәнәйде!

* * *

Мин – династияне дәвам иттерүче. Бабам да МТСта эшләде, хәзер мин дә МТСта эшлим.

* * *

Башка кешеләргә охшамаска тырышсаң, башка кешеләргә охшамаска тырышучы көтүгә иярергә мөмкинсең.

* * *

Зоокибеттә бөтен нәрсә бар, тычкан агуы гына никтер юк.

Чит ил Кыш бабайлары

- АКШ – **Санта-Клаус**
- Финляндия – **Йоулупукки**
- Азәрбайҗан – **Шахта Баба**
- Дания – **Юлеманден**
- Камбоджа – **Дед Жар**
- Камерун – **Тинга-Тинга**
- Македония – **Дедо Мраз**
- Венгрия – **Микулаш**
- Мальта – **Сан-Никлау**
- Монголия – **Увлин Увгун**
- Норвегия – **Юлебукк**
- Төрекмәнстан – **Аяз Баба**
- Лаос – **Канакалока**
- Эстония – **Йыулувана**
- Япония – **Хотейошо**



Беләсең килсә...

1 Элек Россиядә Яңа елны кайчан бәйрәм иткәннәр?
а) 1 майда;
б) 1 сентябрьдә;
в) 1 апрельдә.

2 «В лесу родилась ёлочка» җырының текстын кем язган?
а) Раиса Кудашева;
б) Раиса Блох;
в) Рәйсә Борһаниева.

3 «Ирония судьбы, или С легким паром» фильмы ничәнче елда төшерелгән?
а) 1975;
б) 1976;
в) 1977.

4 1991 елның 31 декабрендә илбашы урынына россиялеләрне Яңа ел белән кайсы артист котлады?
а) Михаил Евдокимов;
б) Михаил Задорнов;
в) Михаил Ефремов.

1. б); 2. а); 3. а); 4. б).

Сканворд җаваплары

Горизонталь: абага, гала, ТТ, Рәйхан, Сая, чабан, дәрья, ур, үҗәт, маршал, әчкелт, Хорошо, чишмә, алу, Рин, Тина, адресат, армия, ут, театр, ба, җим, Искәндәр, ЛуАЗ, ял, Динара, Ана.

Вертикаль: ясту, чабата, Җәлил, ре, ядәч, Шушма, Данир, әткәм, Итил, до, әр, ярсу, шагыйрь, Иа, казна, га, ямтхунд, бәз, Ан, Балтач, Руан, яра, Атна, раритет, дала, буш, ис, җә, Фаракшина, ир, атом.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Газетаның киләсе саны 6 гыйнварда чыга.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15344 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 394

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+